*Нәҗибә Сафина*

# Таң кошы



*Нәҗибә Сафина*

# Таң кошы

ШИГЫРЬЛӘР

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1997

ББК 84(Р-Тат)-5
С24

**Сафина Нәҗибә**

С24 Таң кошы: Шигырьләр.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1997.— 127 бит. Рәсеме белән.
ISBN 5—298—00873—9

Шагыйрә Нәҗибә Сафинаның бу китабына төрле елларда язылган шигъри үрнәкләре кертелде. Китап «Дөнья» дип аталган бөек китапны ача башлаучы яшьләргә дәшә.

**С $\frac{4702560202—083}{М132(03)—97}$ 45—97** **ББК 84(Р-Тат)-5**

ISBN 5—298—00873—9

© Татарстан китап нәшрияты, 1997

# УЙГА—ЮЛ, ҖАНГА—ҖЫЛЫ!

*Язгы ташкын,*
*күзге балкыш—*
*Берсе дә түгел лә мин.*
*Мин барысы да,*
*мин тик кеше—*
*Яшәүнең күге лә мин.*



## *Юк, килмәсен миңа охшаш таңнар*

Иртәгә дә әгәр
Нәкъ шундый ук
Таңнар атса, димен,
Нишләрмен?
Иртәгә дә
Кабатланыр өчен
Тезелеп торса шул ук
Эшләрем?

Юк, килмәсен миңа
Охшаш таңнар.
Туганы, дим, булсын
Алырак.
Көн тууга миңа
Җырлап торсын
Яңа җырны яңа
Яфрак.

Яңа таңда тусын
Яңа сабый.
Картайганнар булсын
Яшерәк.
Егет-җилән булсын
Җитезрәк.
Кайгы-хәсрәт килсә,
Әзерәк.

Офыкларым
Күтәрелсен биек.
Хыялларым очсын
Арырак.
Тауларым да булсын
Биегерәк.
Бөркет ояласын
Бирерәк.

Җилләрнең дә юлы
Төрле булсын,
Кәккүкләрнең моңы
Башкача.
Мин бәхетле түгел
Юлларымда
Кыр боланы күшәп
Ятмаса.

Юк, килмәсен миңа
Охшаш таңнар.
Туар таңнар булсын
Алырак.
Картаймасын кеше,
Гел яшь булсын.
Шатлыклар — күп,
Кайгы — азырак.

## *Җанавылда туып үскән без*

*Сәҗидә Сөләймановалы*
*искә алу кичәсендә*

Кай җирләрдә туып үскән, диләр,
Нинди җир ул диләр, Яңавыл?
Яңамы ул, әллә ян авыл-мы?
Шигырь булып җанда яна ул.

Һәр адымы белән яңа ул!

Галим-голәмәләр, баш ватмагыз!
Ян диеп тә, яңа диеп тә.
Җаныбызны яшереп яшәдек без,
Моңга салып, янып, көеп тә.

Ул эндәште безне биеккә!

Яңа авыл түгел, ян авыл да.
Җан авыл ул, дуслар, җан авыл!
Туып үсү түгел, бер күрсәң дә
Мәңгелеккә җанда кала ул.

Аксакал ул, сабый бала ул!

Инде бүген килеп сер чишәбез:
Җанавылда туып үскән без.
Сәҗидәләр, Нәҗибәләр булып,
Шигырь дөньясына күчкән без.

Моң касәсен чумырып эчкәнбез!

Ишморатлы, Гайнан Әмирие,
Нурихалы, Илдар Юзие! —

Җанавылы булган кешеләргә
Шәһре Казан һәрчак үз өе.

Җанавылның анда үз көе!

Һәр татарга кадерле ул Казан,
Дошман гына аны алганмы?!
Үз баласы итеп каршылый ул
Җан авылдан иңгән җаннарны.

## *Туктап тормый дөнья*

Син сүгәсең мине ахмак, диеп.
Акыллым, дип, кайчак сүгәсең.
Мин кылмаган гөнаһларны ягып,
Күпме йөз суымны түгәсең.

Хыялыңны, бәлки, эшкә җигеп,
Фәрештә дә миннән ясыйсың.
Син дигәнчә түгел дөнья, диеп,
Күпме колак итем ашыйсың.

Мин дигәнчә түгел дөнья, беләм.
Син дигәнчә әллә барамы?
Әнә бүген шуның өчен дә бит
Синең, минем дөньям яралы.

...Димәгәнчә, тоймаганча бара,
Сөймәгәнчә бара, бара бит...
Син дигәнчә, мин дигәнчә түгел,
Җанда синең кадәр яра бит.

Туктап тормый дөнья, бара бит...
...дөнья яра бит...

## *Үз-үземә генә...*

Үз-үземә генә ачуланам:
Дулкын кебек «кайта-китәле» мин.
Килеп бәреләм дә ярларыма,
Кабат дәрьяларга китәмен мин.

Үз-үземә генә ачуланам:
Табигатьнең нәни баласы мин.
Үзем генә ярган ярларымда
Елга җыры булып агасы, дим.

Үз-үземә генә ачуланам:
Үз җаныңны тыеп, кыеп кара...
Үз-үземнән киткән мизгелемнән
Җанымдагы һәрбер бөтәү* яра.

## *Менә шулай!..*

Бу дөньяга ничек килгәнемне
Хәтерләмим мин дә.
Туган телдә тәүге бишек җырын
Мин ишеттем синдә,
Башкортостан — мәгърур Урал иле.
Бишек җырым минем — тәүге җырым —
Тукай теле иде,
Шул җыр белән җанга килеп керде
Бөек Тукай иле.

* Төзәлми торган яра.

Татарстан — моңлы Әтил җире.
Тәүге тапкыр тәпи баскан туфрак
Башкортостан булган.
Күңелемә тәүге бию көе —
«Әпипә»ләр тулган.

«Пар ат»ларны ятлап җырлаганмын,
Тукай «Пар ат»ларын,
Әлифбадан Урал өнен генә —
Курайны тапмадым.
Балачакның гамьсез күзе белән
Караганмын җиргә.
Чын күңелдән мин бит инанганмын —
Бу ике тел бергә.
Арымас та, аерылмас та сыман
Агыйдел һәм Чулман —
Икесе дә күңелем буйлап агып
Җан чишмәмә тулган.

Бүген килеп миңа берәү әйтә:
«Чишмәң буталган, — дип, —
Бер елганың җанга агымнары
Янә тукталган бит».
Идел агымнарын туктатырга
Әллә әмер бармы?
Халык күңеле әллә саеккан да,
Җан ишеге тармы?
Җаным синдә минем, Татарстан.
Җирем — Башкортостан.
Кеше булып мин соң яши алам
Кайсыннан баш тартсам?!

## *Тукайга дәшү*

Нихәл, Тукай?
Җанда нинди гамьнәр?
Таш сыныңны сыгып аумыйсыңмы?
Җан җылысы эзләп сиңа килдем,—
Эшләр кая бара, аңлыйсыңмы?

Дөнья кызу!
Җан әрнүдән тора.
Таш булсаң да, елый алмыйсыңмы?
Ташлар булып ташлар ыңгыраша,—
Дөнья кая бара, аңлыйсыңмы?

Анда ташлар,
Монда башлар ава.
Коллык богауларын таныйсыңмы?
Җан кадәрле җанны кол итәргә
Инквизиция бара, аңлыйсыңмы?

Анда таулар,
Монда олуг Идел
Аягүрә баскан, тоясыңмы?
Салым түләгәч тик яктыртырга
Фәрман чыгарылган Кояшыңа.

Агач төбе,
Ат аунаган төге,—
Барысына да салым салынган бит!
Милләттән җан, мөлкәте һәм аңы,
Җирнең мае сыгып алынган бит.

Нихәл, Тукай?
Монда шундый хәлләр.
Таш сыныңа килдем җылы эзләп.
Җаннарда таш, таштай ауный башлар.
Киселәләр алар йөзләп-йөзләп!

Нихәл, нихәл,
Тукай атлы әрнү?
Мин Нәҗибә атлы җан ярасы...
Тау ватканчы әле кирәк иде
Тузаннарга, тауга табынасы.

Нихәл, тарих —
Олуг Тукай атлы?
Монда тузан сулышларны каплый.
Җаннарда да хәзер тау ярасы,
Тауларда да икән җан ярасы, —
Бер Аллага калды ялварасы!

Дәш, Таш Тукай!
Җанда нинди хәлләр?
Таш сыныңны орып аумыйсыңмы?
Җаннар хәзер таштай катып калды,—
Таш Тукаем, мине аңлыйсыңмы?
Таш Тукаем, безне аңлыйсыңмы?
Таш булсаң да, әллә аглыйсыңмы?
Күз яшьләрен безнең таныйсыңмы?!

## *Кисәтәләр безне Исхакыйлар*

Кеше туды, җиргә аваз салды,
Ишетте дә дөнья хәйран калды:
Җаннарына яра ера-ера,
Яшәүләре ялгыш юлдан бара.

Ни кылырга, ничек төзәлергә...
Кем гаепле, кемне җәзаларга...
Гаепсездән гафләт басканнарны
Нинди чара илә араларга?

Тау-ташларга, болытларга гына
Асылынып кына калды сорау,
Алай итсәк, болай итсәк булмый,
Ләкин болар юрау, фәкать юрау.

Һәм...
Һәрдаим тикшерелгән ысул
Хәрәкәткә килде, хәрәкәткә:
«Яра калсын, каны күренмәсен,
Йозак салып куйыйк җәрәхәткә».

Һәм салынды йозак, озак-озак
Сүтелмәде җанга корган тозак.
... Хакыйкатьтән торган рухи орлык
Кабат шытасын Ул белеп торды...

Белеп торган өчен бикләделәр,
Бикләделәр Гаяз Исхакыйны:
«Кәеф-сафа тулы дөньябызны
Бозарга,— дип,— аның һич хакы юк».

Телне кисеп, йозак салып куеп,
Туктатырга мөмкин түгел чирне.
Олы авыру бер кагылган икән,
Таркатырга мөмкин бөтен Җирне.

Менә шуны кисәтмәкче иде
Ил хаклары торган Исхакыйлар.
Хәтта ташның үз теле барлыгын
Исбат итте безгә Моң-Бакыйлар.

Гасыр аша инде өн ишетәм:—
Исхакыйлар дәшә дип хис итәм:
«Киселдеме телең—ишелдеме илең...
Тарих исбат итә кемнәрнең кемлеген!»

## *Шагыйрь белән сөйләшү*

*Рәшит Әхмәтҗановка*

### I

— Кабереңне кояш күргән көннән
Саный икән халык сине үлгән.
Кояш күрмәсен, дип, кабереңне
Таң атуга ап-ак карлар күмгән.

Язлар җиткәч, ничек түзәрсең соң?—
Кеше сүзе авыр кагылыр бит.
Кабереңә килеп баш исә дә,
Үлгән диючеләр табылыр бит.

### II

— Җәй җиткәч тә терелә мин, бәгырь.
Җир өстенә алып чыгар үлән.
Җирдә җыр һәм үлән исән чакта
Әйтеп карасыннар: «Рәшит үлгән».
Мин бит монда, бәгырь, тик шулай дип,
Көлгәннәрдән көләр өчен килгән.

# *Кеше — шигырь...*

(Туган көндә гәпләшү)

*Роза ханым Туфитулловага*

Дөнья, беләсезме, нидән тора?
Күләсезме? Анысын беләсез.
Беләбез дип уйлап, көлә-көлә,
Әмма белә-белә бәләсез.

Дөнья юктан гына тора, юкса:
Кояш чыгу, кояш батудан.
Бату белән чыгу арасында
Кочаклашып йоклап ятудан.
Менә шулай, Роза,
ә калганы проза.

Дөнья тора тагы юктан гына:
Яфрак белән яфрак арасы.
Яфрак өзелгәндә ярасына
Яңа бөре ялырып каласы.

Дөнья тагы шунсыннан да тора:
Сөзелүдән тора, өзелүдән.
Тигезләргә диеп басканнарның
Аяк асларында изелүдән.

Тагы шуны белүдән дә тора:
Изелү ул — түгел тигезләнү.
Тигезлимен диеп тилергәннең
Каршысында түгел ул тезләнү.
Менә шулай, Роза,
ә калганы проза.

Дөнья, беләсезме, нидән тора?
Баскан саен үзләнүдән тора.
Югалтуын аңлый алса кеше,
Бөрөзлексез эзләнүдән тора.

Эзләнүдән тора һәм табудан.
Табынучылардан һәм «табу»дан.
Куып җитәм, диеп, бу дөньяны
Туктый алмый бер мәл гел чабудан.

Әле тора туктап тын алудан,
Үткәннәрдән гыйбрәт алудан.
Үткән мизгелләрнең оч-очларын
Ялгый алмый гаҗиз калудан.
Менә шулай, Роза,
ә калганы проза.

Мизгелләрдән тора, ә мизгелләр
Үз ярларын табып җыелалар.
Кеше гомерендә мизгел булмас
Пүчтәкләре аның җуелалар.
Менә шулай, Роза,
ә калганы проза.

Ә менә бу мизгел җуелырмы?
Гомер ярларына җыелырмы?
Гомерләрнең калган яртысында
Яшен генә булып тоелырмы?
Сорау туа, Роза,
ә калганы проза.

Дөнья тора теләк теләүләрдән.
Теләкләрнең чынга ашуыннан.
Теләгәннәр инде юш килде дип,
Күңелләрнең күккә ашуыннан.



ЦБС ... района ... АССР
абонемент

Тагы әйтәм дөнья нидән тора:
Бер-береңә изге уй кылудан.
Айкалудан тора, чайкалудан.
Бар дөньясы хәер сорашканда
Рухың белән исән, бай калудан.
Кеше — шигырь, Роза,
ә яшәү — проза.

## *Язгы этюдлар*

Тулган бөреләргә бәреләдә,
Эреп китә карлар.
Майда — буран, кышын — ләйсән яңгыр.
Тулышканнар ярлар.

Ятим җилләр көздән адашкан да,
Өзәр яфрак эзли.
Төргәгеннән нәни бөре көлә,
Биләү бавын өзми.

Ә алданган каен ботаклары —
Тәрәз төбе гөле.
Бер стакан суда яфрак яра,
Соңгы көне — белми.

Ерткаланып беткән соры болыт.
Кар өстендә гөлләр.
Тотынма, кыш, утка, язны күргән
Юләрләр дә көләр.

# *Төн — төер...*

Төн уртасы. Җанда борчу
Өермәдәй өерелә.
Ачы күз яшем әйләнә
Тамагымның төеренә.

Ул төердә тамчы-тамчы
Җанга төшкән ачы камчы.
Ярасыннан сыкрый җан,
Озак-озак атмый бу таң...

Ул төердә очкын-очкын
Минем җанны өткән уттан.
Җилләр белми шул ут холкын,
Атмаска булгандыр бу таң...

Ул төердә адым-адым
Атланылмый калган юллар.
Әйтерсең лә шушы төнгә
Сыйган зая үткән еллар.

Төн уртасы, ә җанымда
Утлы ташкын актарыла.
Җаным түзми, хыялында
Кайта туган якларына.

Туган җире су астында.
Йә атсын да ди таңы да.
Күгеп утлы чылбыр каплый,
Җанның уты төнгә капмый.

Таң аттымы, тагы күңел
Эзли яшьлегенең күген.
Тәпи баскан туфрак кадәр
Бернигә юк җирдә кадер.

## *Яшәүнең күге лә мин*

Мин ни өчен бу дөньяга
Нәкъ кеше булып кайттым?
Ник гөл кебек чәчәгем юк?
Күбәләк күк канатым?

Нигә соң очар кош түгел,
Сөюгә тугры аккош?
Йә булмаса, бер мизгеллек
Җанга иңәрлек балкыш?

Нигә яшел яфрак тулы
Ап-ак каен түгелмен?
Чылтырап аккан чишмәнең
Җыры гына күңелем.

Нигә, нигә, нигә, нигә
Уй булып түгеләмен?
Аккош, чишмә, балкыш, каен,
Күбәләк күңел лә мин.

Яфраклар булып саргаеп
Күзләрдә түгеләмен.
Ярларда ярсулы ташкын,
Биләүле бөре лә мин.

Язгы ташкын, күзге балкыш —
Берсе дә түгел лә мин.
Мин барысы да, мин тик кеше —
Яшәүнең күге лә мин.

## *Шәһәр тәрәзеннән карап...*

Язгы иртә:
Тып-тып итеп
Түбәләрдән тама тамчы.
Тәрәземнән карап калдым
Мин берәүне күз алдымнан
Ерак китеп югалганчы.

Тып итеп
Исемә төште:
Тып-тып тибә йөрәк кенәм,
Акыл мине туктатмакчы,
Ялгышасың, дигән булып,
Үзе түгел, өрәк кенә.

Акыл — юләр,
Юатмакчы,—
Аны тагын югалтмакчы.
Өрәк кебек бәргәләнеп,
Югалганны мин тапмакчы.

Шәһәр, шәһәр —
Фәхеш иле...
Гаеп итмәсеннәр мине...
Бардыр анда төрле кеше,
Сызланучы минем ише.
Адашканны шәһәр йота,
Белмим, шулай нәрсә ота?

Язгы иртә —
Ул да китә.
Иртәгә ул башка булыр.
Җанга башка гамьнәр тулыр.

Язгы иртә.
Шәһәр киртә
Аның белән минем юлга.
Унсигездә сөйгән егет,
Синең хакта уйлавым ла,
Шәһәр тәрәзеннән карап,
Сине уйлап елавым ла.

Әллә чынлап пәйда булдың,
Әллә күзгә күренәсең,
Унсигездә сөйгән егет,
Урам аша син узасың...
...Таяк тоткан әби мин ул,
Син күтәреп торгызасың...

* * *

Идел суы кебек төссез дә син...

*Ә. Атнабаев*

Идел суы бүген төссез түгел,
Теләгәнең сайла гамманың.
Күрәзәче булалмады шагыйрь,
Акланмады сүзе Әнгамның.

Калды тик аракы төссез булып,
Төссез итте бөтен дөньяны.
Хәтта икмәккә дә туйды халык,
Тик хәмергә генә туймады.

Шуңа дөньясыннан туйганы.

## *Уйга — юл, җанга — җылы!*

«Мой мозг, до знаний жадный как паук,
Все постигал:
недвижимость и движенье —
Но толка нет от мыслей и наук,
Когда повсюду им опроверженье».

*Владимир Высоцкий*

Сүзләр гади — миңа шатлык кирәк.
Шатлык мизгелләре бигрәк сирәк.
Уйга — юл да, җанга — җылы гына,
Яшәү өчен бары шулар терәк.

Тик түрәләр «Бес — үсепес» диләр.
Фикер сорамыйлар — кирәкми.
Тыныч кына яшик әле, диләр,—
Борчып йөрмә, диләр, йөрәкне.
Синең өчен таяк кадалган бит
Бу дөньяда, кабер өстенә дә.
Күрсәтелгән җирдән ары китмә,
Булсын безнең фәрман көчендә лә».

Фәрманнарның «тылсым көчләре»нә
Ышанмаган өчен җәзалыйлар.
Бу дөньяда синең белән яшәү —
Яшәү түгел, бары каза, диләр.

Алар каккан казыкларны җыйнап,
Кабык ясап куйдым соңгы юлга.
Урыс табутына салалар да
Ташлап калдыралар — күрәм ел да —
Ләхет эчләренә гәүдәләрне,
Табут торып кала җир өстендә.
Күңелемә ел да авыр була:
Кызыл табут — табут кан төсендә,
Торып кала тагы җир өстендә...

## *Шул чагында, бәлки...*

Аклыкларга аклык өстәп кенә
Коелалар карлар.
Күңелемдә эремичә калган
Ак кар таулары бар.

Салкын саклап йөремәскә диеп,
Килешмәскә дә бит.
Кар өстенә карлар явып тора,
Бирешмәскә дә бит.

Чигәләргә кунган кар бәсләрен
Тарап төшерегез!
Йөрәккәем һаман саклап йөрткән
Хисне кичерегез!

Җылы эзләп төшә карлар җиргә.
Эри — язлар белән.
Җир шарының мәңге туңлыгына
Кайчан язлар килә?

Күңелемдә поляр төннәр туа,
Туа поляр көннәр.
Күңелем буйлап йөри изге, явыз,
Тагы әллә кемнәр...

Булдырмаска иде күңелләрдә
Эремәслек ташлар:
Шул чагында, бәлки, мәңгелек туң
Җирдә эри башлар...

## *Көткәндә*

Назга сусаган кеше мин.
Язга сусаган кеше.
Күңелем китек, эзләп йөрим —
Кая күңелемнең ише?
Ә син, мин түгел, дисең.

Давылга сусаган ич мин,
Әзер ялкын яларга.
Була алам хәтта алла,
Күңелең булса аңарда...
Иш түгелләр алар да.

Ташкыннарны иңнәремдә
Язларыңа ташыйммы?
Синең назлардан мин — давыл
Кыяларны ашыйммы?
Яңа таулар ясыйммы?

Күз сирпеп бер генә карыйм —
Йә, пәрдәңне ач инде...
Тик шулай да кач инде...
Ай үпмәсен кашыңны...
Яшер, яшер башыңны...

...Күңелем китек, эзләп йөрим —
Кая күңелемнең ише? —
Назга сусаган кеше мин.
Язга сусаган кеше,
...Ә син, мин түгел, дисең.

# *Яшьлек атавында*

Гомерләрдә юк тукталыш,
Туктап калмагыз ялгыш.

Ә яшьлегем туктап атавында,
Чылбырланган көймә шикелле,
Кабатламак булды мин кайчандыр
Югалткан бер изге мизгелне.

Без үткәндә икәү салган сукмак,
Без утырган ак таш, кая син?
Үткәннәргә чыкма икән юлга
Тирәнәйтеп күңел ярасын.

Без утырган олы ак таш тәхет —
Учымдагы яссы тәтиме? —
Чая дулкын, кая алып киттең
Тәхет өстендәге бәхетемне?

Кабатламак булды шул ак мәлне,
Ялгышларын ташлап упкынга.
Сандугачы таңның калды йоклап —
Картайганмы әллә чукынган...

Ә мин, җүләр, кабатламак булдым
Югалтылган изге мизгелне...
Ярда ятам иреннәрне чәйнәп,
... Чылбырланган көймә шикелле.

## *Үтеп барышлый*

(Такташка ияреп)

— Хәзер сулар гел агулы.
Авыр эчәр сулар табуы.
— Менә шуңа да мин эчәм аракы.
Эчәргә су булмаганга яраклы.

*(Сәрхуш белән сөйләшүдән)*

Автобуска берәү килеп керде.
Керде дип ни, ул шуышып менде.
Өстендәге агып торган ләмгә
Буялудан куркып мин чигендем.

Ямьсез көлеп әйтеп куйды сәрхуш:
«Нәрсә, әллә чиста калмакчысың?
Барыгызның җаны сазга баткан,
Инде Җир-анадан качмакчысың.

Җирдә яттым, җирдә йокладым мин.
Миңа яхшы фатир бирмәделәр.
Урман урлап, йорт салмакчы идем,
Синең өең, әнә, төрмә, диләр.

Ну, анда да була көн күрергә.
Кояшны бит тотып ябалмыйлар.
Галимнәре көчсез — шул кояшны
Сүндерергә әмәл табалмыйлар».

Автобуста халык телсез иде.
Сәрхуш өчен урын бик киң инде.

Бар «аек»лар өелделәр бергә,
Сузылып ятты сәрхуш зу-у-ур
идәнгә.

«Менә инде, диде, кояш сүнде.
Бөтенегез шушы хәлгә күнде.
Мин бит инде әллә кайчаннан җир,
Тик таптарга җирәнәсез мине».

Автобуста халык өнсез иде...



# ЧАЛЫ КОШЫ

*Хәзер инде*
*Кызыл гына түгел әләмнәр.*
*Кызыл гына түгел адәмнәр...*
*Тик салават күпере*
*һаман бертөрле,*
*Үзгәртеп кормаганнар*
*ул күперне...*



## *Башка язмыш юктыр...*

Зәңгәр моңлы, алтын кояш нурлы
Күгем гүя бүген күгәргән.
Авыр миңа — көннең болытларын
Күз кабагым белән күтәрәм.

Карлар түгел, зар түгелер төсле
Ул яшәреп аккан болыттан.
Минем җаным зар болыты белән
Кышкы яшеннәргә юлыккан.

Зар яумасын җиргә, сабыр бул, дип,
Болытларны төйим җаныма.
Син җанымны кара болыт иттең,
Аяз чагын башка сагынма!

Җылы куллар тисә, яңгыр ява,
Салкын куллар тисә, кар гына.
Кояшларым бар да синең күктә,
Күңелемдә калган зар гына.

Зарларымны кысам — җыр чыга.
Башка язмыш юктыр җырчыга.

* * *

Учак яна — җылыналар.
Якынрак җыелалар.
Аннан таптап сүндерәләр.
Утны шуңа күндерәләр.
Ә мин — кеше, учак түгел —
Сынса сына, сүнми күңел.

* * *

Җир бар, җыр бар, чор бар.
Син бар, мин бар — сер бар.
Җирне, җырны чорга бәйләп,
Мәңгелек сер гел әйләнә
Утлы Кояшны тирәләп...

* * *

Исерекләр илне баскан,
Галимнәр үз илен ачкан.
Җансыз калганга гәүдәләр,
Фәрештәләр илдән качкан.

## *Ачыл, бөре!..*

Ачыл, бөре, ачыл гына,
Ялкын йә салкын булса,
Яфрак диеп аталырга,
Яшәргә хакың булса.

Агачка тел булырсың да,
Җилгә салырсың сүзең.
Яңа бөрегә җан биреп,
Җиргә төшәрсең көзен.

Ачыл, бөре, бөтерелеп
Кала күрмә көзләргә!
Ак җилләргә җаның ачып,
Туры килер түзәргә.

Беләм ак җилләр холкын.
Мин дә буранлы ташкын.
Ак җилләр кочагына
Абайламыйча таштым.

Бөре! Мин — туң йөрәкне
Аңлый алырсыңмы соң?
...Җаным бит җил иркендә.
Буйсындыралмый кем дә...

Ачыл, бөре, ачыл син!
Мин дә бер ачылырмын.
Яфрак булыр көннәремне
Уйлап бер басылырмын.

## *Яшел юлдан*

Казаныма кайттым.
Әй, Казаным!
Идел-суың нидән саеккан?
Әллә туктаганмы агышлары
Агыйделнең, бәлки, Җаекның?

Уйларымны гүя, укыгыз, дип,
Үпкыннарың төбен күтәргән.
Гүя күк капусын ачыгыз, дип,
Әллә ничек күгем күгәргән.

Табигатькә әллә ниләр булган:
Күзләр мөлдерәмә, күлләр сай.
Күзләр әйтә: безгә ирек даулап,
Тагы бер кат түнтәрелгән ай.

Август икән. Казан, сиңа кайттым.
Утызынчы август — чор башы.
«Ирек» диеп башланырга хаклы
Татар милләтенең җыр башы.

Казаныма кайттым, Азаныма!
Бисмиллаһи иррахман рахим.
Соңгы тамчы каным тамса тамсын,
Ирегемне юк шул бирәсем!

Утызынчы август — язмабызны
Яшел юлдан башлау сәгате!
Кызыл төстә — тыю галәмәте.
Яшел төстә — яшәү халәте.

## *Уйны өткән мизгелләр*

* * *

Ут булсаң да, бер юллыктан йөреп була.
Үз-үзеңне корым белән төреп була.
Ярый ла ул кабызалсаң корымны да,
Җанны ялмар ут италсаң җырыңны ла.

* * *

Трамвайга салган юлдан
йөреп торам.
Ваемсызлык булып җанга
оялаган ике елан.

Ике елан әйтеп тора:
«Миннән китмә, үзеңнән кит!»
Җанда зәгыйфь кенә тавыш:
«Трамвайга утырма!» — ди,
белмим, ничек?..

* * *

Мәрмәр дивар. Күксел ылыслар.
Ак гөлләргә чумган ильичлар.
Йортның нигезенә сыенып,
Лишайлы эт елый сыгынып.

## *Кояш белән сөйләшү*

— Исәнме, әй, саумы, Кояш!
Нихәлләрең бар?
Мин җирдә, исән-сау да ул,
Дөньям тулы зар.

— Мин исән-сау әле, бәндәм,
Елыйсың икән.
Син дөньяны яктыртырга
Уйлыйсың икән.

Миңа карап уйлан әле,
Әй бәндәм генәм!
Нидән мәңге утта яна
Кояшың гелән?

Үз-үзеңне кабызмасаң,
Дөнья караңгы.
Чакматаштай кабыналсаң,
Ямыйм яраңны.

* * *

Шаша, таша елгалар,—
Тотып торалар ярлар:
Берсе — текә, берсе — сөзәк...
Берсе — акыл, берсе — йөрәк.

## *Көзге таган*

Табигатьтә моңсу тынлык бүген.
Ыгы-зыгы шәһәр урамы.
Мин җаныма тынгы таба алмый,
Шул урамны күпме урадым.

Өрәңгеләр минем иңнәремә
Учлап-учлап яфрак түктеләр.
Сары, кызыл, яшел, соры төсләр
Агачларны ташлап киттеләр.

Яфрак төшкән саен җил иркендә
Калтыранып куя чаганнар.
Шәрә калган чаган ботагында
Кемдер элгән аркан-таган бар.

Җилдә тибрәнгәләп кенә төшкән
Яфрак итеп тойдым җанымны.
Әйтерсең лә бала чагым кайтып,
Томалады минем аңымны.

Вакытларны борыр көч бар икән
Көздә яфрак янган заманда.
Аркан-таган шәһәр урамында,
Күңел дигән бала таганда.

* * *

Аквариум балыгына
Әйләнә күрмә, халык!
Савытың ватмый гына,
Җаныңны якмый гына
Табылмый җирдә хаклык...

* * *

Иртәгәгә кабызырга
Томалыйлар күмерне...
Кабызалырмы Киләчәк
Бүген сүнгән гомерне?

* * *

Дөнья бер мантыйксыз, фәлсәфәсез
Әйләнгән чакта,
Хәер сорап тора икән
Фәйләсүф — чатта.

...Дөнья — җыр ишетми — туптан
Атылган чакта,
Сүгенергә мәҗбүр, имеш,
Сандугач хәтта!..

## *Башкача юк*

Татар каберендә ләхет булган, ди.
440 ел элек бәхет булган, ди.

Каберенә ләхет уеп, татар
Куя иде сүнгән гәүдәләрне.
Өмет тота иде, җыя иде
Ирек килер, дигән бәндәләрне.

Ләхет тота иде томаламый
Авызларын шушы гәүдәләрнең.
Ләхетләрне җимерүче булып
Күз алдымда бүген гәүдәләнден.

Үз җиремнең туфраклары бүген
Авызымны килеп томалады.
Ничә гасыр йомшак җәя-җәя,
Баскак көчләр безне юмалады.

Ләхетендә сулар һава табып,
Үлмим, диеп яткан татар бүген
Киңәйтмәкче иде ләхетенең
Бераз хет өйләнеп ятар күген...

Өскә баскан аяк сизеп алды,
Ләхет күге тагы авырайды.
Кол булганчы үтер, баскын, диеп,
Аяк асларына аваргамы?

Син җантимер булсаң, әйт:
«Мин — тимер!
Халкым өчен ирек калканы», — дип.
Шаярмагыз халык хисе белән,
Мәйданнарда бүген гасырларча
Яшерен янган йөрәк ялкыны бит!

Һәм кул куйма коллыкнамәсенә,
Ләхет түгел, бәхет кирәк безгә.
Коллыкнамәсенә кул куймам, дип,
Туры карап әйт син бүген йөзгә!

Баш өстенә икмәк куеп әйтсәң,
Ышаначак халык синең сүзгә.
Башкача юк!

## *Кыр казлары минем халәттә*

Мин кыр казы
Булдым инде, ахры.
Очып йөрим ике арада:
Торган җирем белән Туган җирем —
Җаным минем ике ярларда.

Кыр казлары
Булдым бугай инде.
Кайтам Яңаулга, Казанга.
Туфрагыма ятып назланамын,
Җаным сарсый моңлы азанга.

Кыр казларын
Аңладым да бугай:
Кыр казлары минем халәттә.
Туган җирдән күтәрелә алар
Җаннар җырга узган сәгатьтә.

## *Төрмәләр һәм парламентлар...*

Дөнья тора вөҗдан үлчәвендә,—
Тәлинкәләрендә ике төр зат:
Берсе — зиндан, берсе — парламент.
Кешеләр — бер, башка — орнамент.

Икесен дә бер иләктән или:
Җыелалар сайлап, сайланып.
Икесендә дә «әйбәт» утыралар
Һәм бетәләр тәмам майланып.

Үлчәү генә кайчак тибрәнгәләп,
Төшергәләп тора «майлылар»ны.
Әле анда, әле монда салып,
Бутап кына тора «җайлылар»ны.

Дөнья үлчәүләре түнтәрелә,
Тәлинкәнең монысы күтәрелә.
Вөҗдансызлар төрмәләргә түгел,
Инде парламентка үткәрелә.

Шундый заман килде, замандашым,
Сагынасыңдыр «анда» үткәнеңне?
Кыйблаң очты, инде белмисеңдер
Кайсы тәлинкәңне сукканеңне?

Дөнья тора вөҗдан газабында.
Тәлинкәләрендә тик ике зат:
Урлаган һәм урланганнар алар,
Тик бер генә түгел, кабат-кабат.

## *Утлы уй*

«Утны яндырыр өчен дә,
сүндерер өчен дә сакларга кирәк».

*Әткәй нәсыйхәтеннән*

Кайчакларда утны сүндермәскә,
Мамыкларга төреп саклаганнар.
Утны, суны, телне һәм намусны
Һичкайчан да ләкин сатмаганнар.

Кайчакларда утны сүндермәскә
Утын булган кура-киртәләре.
Сәкесез һәм җир идәндә генә
Каршылаган Кеше иртәләрне.

Утны сүндермәскә, шашып аккан
Елгаларны буып туктатканнар.
Кешеләрнең учагына түгел,
Бәгыренә шулай ут якканнар.

Наз белән бер, яз белән бер бит ул.
Тауларда бер, далада бер холык.
Учакта — бер, җанда — икенче ул.
Кызу янган утта һич төтен юк.

Саклый белсәң генә сүнә дә ут.
Саклый белсәң генә кабына ла!
Утны кеше түгел, ә кешедән
Саклар заман җитте, йә Хода ла!

Суны бума — суның үз юлы бар.
Утка-суга мәңге табыналар.
...Саклый белмәгәнгә илсез, җирсез,
Җансыз калганнар да табылалар.

* * *

Төн.
Караңгы белән түгел,
Уй белән тулы.
Иңнәремә, әнә, кагыла
Кемнеңдер кулы.

Ул
Куллары белән түгел,
Нур белән сөя.
Минем янга ашыгадыр,—
Хөлләсен кия.

Мин
Күңел капкаларымны
Каерып ачам.
Килеп керсә, тапмасын дип,
Айга ук качам.

Ай
Кычкырып көлә миннән:
«Килми!—ди бүген,—
Килсә, ташлап төшәр идем
Үзем дә күгем».

## *Үзгәрә икән заман...*

Төш күреп ятам әле —
Авылга кайтам әле.
Ә анда шундый болын —
Мин генә беләм юлын.
Каеннан алам тузны,
Тырыска салам тозны.
Әбинең күзләрендә
Һәм әйткән сүзләрендә
Кояш та бар, ае да.
Чүлмәк тулы мае да.
Уянам. Кая авыл?
Кайда чүлмәк — каравыл!
Уянам — юк әби дә.
Авылда юк бер өй дә.
Ә әби? Җылы караш?
Болын өстендә кояш?
Болын инде юк, диләр.
Болын китәме, юләр!
Төшме бу? Юк болында
Уйнап йөрми колын да...
Төш түгел бу — шул заман
Үзгәрә икән һаман.
Болыннар, гөлләр кача
Кеше күңеле аша.

## *Ә мин...*

Көн дә хата,
Көн дә тәүбә,
Көн дә яңадан башлау.
Көн дә яңадан ярату,
Көн дә яңадан ташлау.

Ә ай, кояш — гел дә иске,—
Йөриләр бер-бер артлы.
Мәңге кавышмас булганга,
Алар мәхәббәт яклы?..

Бер-бер артлы көне-төне,
Язын, көзен, кышларын...
Сөю хисеннән хет бер
Булмый буталышлары...

Ә мин буталып беттем,
Яздан кышларга киттем.
Мәхәббәт көтәм һаман.—
Җанга ап-ак кар яуган...

## *Ә үзем ышанмыйм*

Яшәр өчен,
Кешелеккә
Дәшәр өчен
Килгән идем Җиргә,
Яндырдылар да
Көлемне
Сиптеләрме миргә?

Кая күзең?
Кая сүзең? —
Дип дәшәмен илгә.

Мөлдерәмә
Күзләр.
Катып калган сүзләр.
Халкым җаны
Әверелеп бара көлгә...

## *Җанны чөя...*

Мин җиргә түбән төшкәнмен,
Ә гавам карый күккә...
Шундый да тирән төшкәнмен
Һәм терәлгәнмен төпкә.

Ә кеше кошка кызыга,—
Очканга, канатлыга.
Мин исә иярә алмыйм
Җәяүлегә, атлыга...

Мин төшкән тирәнлек, беләм —
Халык йөзгән тирәнлек.
Җанны да батырыйммы әллә
Хакыйкатькә керәм дип?..

Ә халык дигәнең гали:
Җанын җибәрми төпкә,
Үзе батса бата, әмма
Ул — җанын чөя күккә!

## *Әгәр шулай булса*

Ут булсаң — сүндерерләр.
Су булсаң — сеңдерерләр.
Таш булсаң — йә атарлар,
Җиргә салып таптарлар.
Сүнмә, сеңмә, атылма!
Чит табаннан тапталма!
Тап төшермә затыңа!
Хөкем юк ул үз җиренә
Туфрак булып ятканга!

## *Кирәк иде...*

Кайгыга чумган иделәр,
Мин җыр башладым.
Иңнәренә баскан йөкне
Алып ташладым.

Син кирәксең, диеп, мине
Кочып алдылар.
Мин җырлаган җырны шундук
Отып калдылар.

Аларга кайгы таратыр
Җыр кирәк иде.
Ә миңа башымны салыр
Җир кирәк иде.

# *Мин дә йоклар идем...*

«Таң йокысын йоклыйлар бит аны».

*Әбием нәсыйхәтеннән*

«Таң йокысын йоклыйлар бит аны»...—
Иң татлысы иде таң йокысы...
Инде күптән таңда йоклый алмыйм,
Күптән инде, күптән мин — таң кошы.

Чиктән ашты инде аруларым.
Соң сулышта, ахры, баруларым.
Төзәтмәкче булсам халәтемне,
Җан өшүдән юктыр дарулары.

Гаҗиз булып җанга иш эзләдем —
Тәрәзәмә килеп ай туктады.
Ай нурына тотынып ал таң атты,
Һәм Кояшны болыт каплап алды.

Керфекләргә ятты кургаш болыт,
Йокы килә, булмый Кояш булып.
Кояш — яна, айны — туңа, диләр —
Җанда — Кояш, Ай һәм күпме болыт...

«Таң йокысын йоклыйлар бит аны»,—
Имин булса әгәр туган җирем,
Исән булса әгәр җан ирегем,
Исән булса әгәр Дәүләт-Җирем,—
Таң йокысын мин дә йоклар идем...

## *Котлыйм*

Чын бәхетле булу бармы?
Әллә уйнау гынамы?
Фәкать шушы — бәхет, диеп
Әллә уйлау гынамы?

Җаның туктаусыз ялварып,
Күгәреп торса күңел,—
Кояш та тутык икән,
Ай йөзе чытык икән.

Ерткаланган, ергаланган
Болыт кебек таралдым.
Тапталган, тапланган җирдәй,
Ахры, инде каралдым.

Яраларны кат-кат бәйлим,
Тышка чыгармыйм канны.
Бәйне тотмый, битлек япмый —
Кая куярга җанны?

Бәхет даулый, бәхет юк.
Тәхет даулый, тәхет юк.
Әй бу тынгысыз җанны,
Тәки сатты бит данны.

Инде миннән көләләр,
Теләгемне беләләр.
Үрелмә, диләр, өскә —
Тотып торалар көчкә.

Күпме кирәк бәхет — ал,
Ләкин бәйдә, диләр, кал!
Чыгып бара җан — тотмыйм...
Бәйсезлек белән котлыйм.

# *Чалы кошына*

*С.-га*

Бу дөньяда озак яшәдеңме?
Ничек яшәдең син, чалы кошы?
Язы, көзе, җәйләреме күбрәк,
Гомереңнең әллә салкын кышы?
Әйтәлмисең, сиңа кыш та җылы,
Җәйләрдә дә ак кар булу кирәк.
Кыш зәмһәрләр, җәен чиллә ялап,
Дәшми торучылар хәзер сирәк.
Шуңа күрә дөнья ыгы-зыгы.
Агач тамырлары җир өстендә.
Кытырт-кытырт яфрак ашаучылар,
Җан кыючы җәллад үз көчендә.
Көзге яфрак кебек коелгансың,
Кыелгансыңдыр син, тыелгансың.
Ни хакына сөюдән дә качып,
Оныткансыңдыр син туй буласын.
Кагылырга сиңа куркып торам,
Нәни кош баласы бар торганың.
Ләкин күрүчеләр бар микән соң
Нәни кошның олы җан-урманын?
Безнең урманда да кош кына син.
Безнең урман кыргый гына түгел.
Тукран булып кортын чүпләсәң дә,
Көя саклап йөри күпме күңел.
Бәйрәмеңдә шатлык сүзе көтеп
Торасыңдыр әле, кош баласы.
Алганнарга җитми: бир-бир, бир-бир.
Әле беткән, дисеңме аласы?
Тик шуны бел: алыр нәрсәләре
Калмаганнар бүген кырылып ята.
Бүген кеше ала-сата, ала.
Шушы көнгә төштек сата-сата.

Алдык, саттык, үстердек тә саттык,
Саттык хәтта инде ханбикәне.
Илне саттык, хәтта телне саттык.
Ә кем белә безнең кем икәнне?
Сатар нәрсәбез дә калмады бит.
Татар затыбыз да таркалды бит.
Чалы кошы, сиңа дәшәм әле:
Сайра әле, сайра татарча хет!

. . . . . . . . . . . . . .

Бәйрәм көнне шундый гасабилык.
Гаеп итмә, миндә бу сабыйлык.
Җаным җимерелеп барган мәлдә
Мин рәхмәтле бүген бу бәйрәмгә.
Әмма шәраб түгел бу савытка,
Тутырылган тагы таләп, таләп.
Хайван булсаң, берни түгелдер дә,
Кеше була калсаң, эшләр харап.
Харап язмышыңа башым иям,
Сиңа, чалы кошы, рәхмәт диям.

## *Үзгәртеп кору*

Хәзер инде
Кызыл гына түгел әләмнәр,
Кызыл гына түгел адәмнәр...
Тик салават күпере һаман бертөрле —
«Үзгәртеп кормаганнар» ул күперне...

# *Әллә...*

Тиктормастай чабып йөри
кеше.
Җирнең тарту көче әзәйгәнме?
Чарасыздан, бәлки, зимагурдыр?
Тамырсызга әллә әйләнгәнме?

* * *

Җанымда язгы аҗаган.
Күңелдә көзге күкрәү.
Көзге моң һәм яз ярсуы
Очрашудан бу тетрәү.

* * *

Ак кар ява...
Дөнья баткан ап-ак уйга.
Кулларымны сузып,
Тордым күтәп.
Уч төбемә килеп кунды
Тик бер бөртек.

* * *

Уйлаганым тора ярамаудан,
Бөтен җаным тора ярадан.
Тирә-ягым тора ак булып та,
Пычратып куйган карадан.

Бөтен дөнья тора ярамаудан.
Бөтен дөнья тора ярадан.
Бөтен дөнья тора ак булып та,
Пычратып куйган карадан.

Ничек кенә сабыр итәрмен дә,
Ничек кенә яшәп китәрмен;
Нәкъ дөньясы кебек, мин үзем дә
Актан кара булган икәнмен.



# КЫЯ КАРАГАЕ

*Сикермәкче булабыз да,*
*Ярлар тота —*
*Ярамый!*



## *Дисеннәр...*

Син андадыр,
Ялгыз урмандадыр.
Агачлардан җылы эзлисеңдер.
Көне үтте, бәлки, килер, диеп,
Ай нурында мине күзлисеңдер.

Син андадыр,
Кышкы урмандадыр,—
Агачларга әллә сүз кушасың?
Яфрак кадәр генә йөрәгеңне
Учың белән шулай ник кысасың?

Син мондадыр,
Минем җанымдадыр.
Йөрәгемне тотып тыясыңдыр.
Ак каенның телсез кәүсәсенә
Йөрәгеңне элеп куясыңдыр.

Әй, каеным,
Сөйлә, дисеңдер син,—
Минем йөрәк сиңа кышкы тел.
Мин җәйгәчә яши алмам ансыз,
Син сөйләргә тиеш, шуны бел:

Син андадыр,
Син ялгыздыр анда.
Тел кирәкми җансыз гәүдәләргә.
Ялгыз айга кичә тезләндем дә,
Мин җибәрдем сине әйдәләргә.

Син белгәнсең,
Ышанмагансың бит,
Яучы булалмый шул җансыз ай.
Төн күгенә синең сүзләреңне
Язып куйды барыбер: «Җан
сызлый...»

Син андадыр,
Бәлки, урамдадыр.
Кешеләрдән җылы эзлисеңдер.
Сиңа дигән җылы миндә генә,
Бәгырькәем, никләр белмисеңдер...

Син анда да,
Минем янымда тик.
Тартып алалсалар, сөйсеннәр.
Урманында сыңар яфрак та юк.—
Урамнар да шулай көйсеннәр.

Тик барыбер
Мине — сине генә,
Сине — мине сөя, дисеннәр...

## *Ишетәсеңме?..*

Була микән шулкадәрле ярату?
Карашыңнан күңелемдә таң ату!

Мәхәббәтме шулкадәрле зурлыкта?
Тузандай тик кечерәя тау кадәрле
хурлык та!

Зурдан да зур була ала мәхәббәт.
Зардан да җыр сыга ала мәхәббәт!

## *Синнән миңа...*

Синнән миңа шулкадәр аз кирәк,—
Бер җылы сүз генә.
Синнән миңа шулкадәр күп кирәк,—
Син миңа түз генә.

Шулкадәрле синнән аз сорыйм бит,—
Сөеп кенә кагыл.
Синнән миңа шулкадәр күп кирәк,—
Илһам булып агыл.

Бик аз гына сорыйм, бик аз гына,—
Бары тик наз гына.
Күп тә сорамыйм бит, сөюеңнән
Акылдан яз гына.

Күп тә түгел, аз да түгел инде—
Җаныма яз сорыйм.
Җылы сүзсез, назсыз, җанда язсыз
Мин барыбер корыйм,—
«Аллам бул»,—дип сорыйм.

## *Синең җаның*

Яфрак-яфрак җан ямаулы,
Күз ямау сала җиргә.
Җан ямаулы, җир ямаулы —
Ямау салынмый җырга.

Искергән җаның, искергән,
Ямау да тота алмый.
Күзгә яфраклар ябынып,
Йоклап та китә алмый.

Сине күптән салкын үпкән,
Җаның җыртылып беткән.
Ярый, җырың ертык түгел —
Халкың зарыгып көткән.

## *Дисәң...*

Көн кояшсыз, төне айсыз булса,
Дөнья тоташ болыт.
Мәхәббәтсез җаннар җирдә йөри
Тоташ болыт булып.

Кышы карсыз, җәй яңгырсыз булса,
Дөнья кибә, көя.
Мәхәббәтсез җаннар җир өстенә
Афәт кенә өя.

Кышына кар, кешегә яр кирәк,
Бәхет булсын, дисәң.
Җанга — ярсу, язга ташкын кирәк,
Ярлар тулсын, дисәң.

## *Шагыйрьгә җавап*

«Илне сүтеп җыясы бар...»

*Мөдәррис Әгъләм*

Халык исән булса, ил сүтелми.
Хаклык исән булса, ул кителми.
Халык җаны кыелмаган булса,
Ватан дигән исем хур ителми.

Илне сүттек, дисең, җыясы бар.
Тарих табын икән — җуясы бар.
Илне баскан җансыз гәүдәләргә
Зәррә-зәррә җаннар куясы бар.

Халык белән хаклык арасына
Тоз сипмәгез бөтәү ярасына!
Шул икәүне аерырга теләп,
Һаман шартлау, һаман Хиросима!

...Минем җанда бүген Хиросима —
Чират басып торам керосинга...

* * *

Хыялга ияреп киттем —
Зәңгәр томан ул.
Зәңгәр томан коча — авам,
Юк шул тотар кул...

## *Синнән*

Синнән кабул итеп алам
көннәрне.
Синнән китерәләр җилләр
төннәрне.
Синнән иңә энгер-меңгер
җаныма.
Синнән генә чыга кояш
таңыма.

Синнән килгән хыялларым
очына.
Чыга алмыйм уйларымның
очына.
Язга, җәйгә, көзгә, кышка
кагылма!
Шуларның хет берәрсендә
сагынмам.

Син булмасаң, мәхәббәткә
табынмам...

## *Шулай була*

Нәрсә булган бу халыкка?
Ник ишетми?
Телен, денен оныткanны
Ул иш итми.

Нәрсә булган бу халыкка?
Нигә дәшми?
Уңдырышсыз җиргә халык
Орлык чәчми.

Нәрсә булган бу халыкка?
Тешен кыскан!
Нидән аның йөзе кара,
Теле кыска?

Шулай була, шулай гына,
Үз-үзеннән
Китәргә дип аңа кушсаң,
Җанын кыссаң...

## *Үзем... бары тик үзем...*

Югалтып карыйсым килде:
Син китмәдең янымнан.
Юатып карыйсым килде:
Еламадың — ялынмам.

Үзем киттем сине ташлап...
Үзем көттем сине башлап...

## *Каз өмәсе*

Авылларда бүген кызлар җыры,
Тальян моңы чыңлый өйләрдә.
Күңелләрдән күңелләргә күчеп,
Кабат яңгырый иске көйләр дә.

Мамык кына гүя — очып куна
Кызлар җыры назы күңелгә.
Иске йолаларны изге итеп,
Муллык җыры җиргә түгелә.

Муллык җыры, салкын ак кар җылы.
Ябалак кар эри уйларда.
Муллык теләп бала-чага кайный,
Каз канаты сибеп юлларга.

Ап-ак карга яуган ак мамыклар
Тузып кала пар ат артыннан.
Кыңгыраулар бүген әбиләрне
Яшьлегенә кабат чакырган.

Авылларда бүген каз өмәсе.
Ак мамыкка дөнья күмелгән.
Һәм әбиләр сүзсез генә җырлый
Үз яшьлеге көен күңелдән.

## *Тәрәзләрең синең*

Тәрәзләрең синең кара пәрдә—
Томаланган,
Салкын кермәсен, дип.
Күңелләрне пәрдә каплый алмый—
Яшерелгән,
Кеше күрмәсен, дип.
    Тәрәзәдән әгәр күз салсалар,
    Туздырылган,
    Өең җыелмаган.
    Кырык пәрдә аша күренеп тора:
    Күңелеңдә хисләр җуелмаган.
«Тәрәзәгез булса, ачыгыз»,—дип,
Мәхәббәттән качма, качыгыз, дип,
Җаныгызга
Сөю уты капса,
Әрәм булачак бит башыгыз, дип,
Җаның тәрәзәсен бикләдеңме?
    Көтмәдеңме,
    Сөю бикне бәреп керер, диеп?
    Үз-үзеңнән киткән мизгелеңне
    Белмәдеңме,
    Ятлар күрер, диеп?
Тәрәзәләреңнең пыяласы
Ник ватылган?
Салкын кергәнмени?
Күңелең бөре булып бөтерелгән,—
Ник ачылмый—
Салкын тигәнмени?
    Тәрәзләрең күпме капласаң да,
    Ачылган бит.
    Ах, яз килгәнмени?
    Күңелләрең тагы туздырылган,—
    Сүтелгән бит,
    Сөю килгәнмени?

## *Әмма...*

Мин барыбер синнән баш
тарталмыйм.
Башкаларга тамчы да
арталмыйм.
Синсез бу дөньяның йөген түгел,
Буш арбасын хәтта тарталмыйм.

Синсез хисләремне таратталмыйм.
Синсез җыя алмыйм таралганын.
Чәчләремне агарткан да тик син,
Әмма хисләремнең түгел
каралтканы.

Мин барыбер синнән китә
алмыйм.
Дөньясыннан китәм, гаеп итмә.
Башка бер көн синсез яши алмыйм,
Миннән иртә китеп, мине көтмә.

Сөюеңне гүргә алып китмә...

* * *

Уттан алып суга салма җанымны —
Әверелермен ташка.
Таш язмышы шундый: бәрсә берсе
Бер гаепсез башка?..

## *Көтәм*

Яныңнан куасың мине,
Килмә, дип.
Син яратмыйсың ич мине,
Көлмә, дип.

Синең җаның, ахрысы,
Минем өй?
Икебезгә уртак өй һәм
Уртак көй.

Җаныңнан куасың мине,
Мин китәм.
Минем җанны бушатуың
Тик көтәм.

* * *

Мин сине дә укып чыктым,
Сәер китап булдың син.
Күңелгә җыр да, сагыш та,
Ачы булып тулдың син.

Җырың — сөю мизгелләре,
Сагышы — югалтулар.
Ачылары — хакыйкатьнең
Җимешләрен татулар.

Мин сине дә укып чыктым:
Авыр китап булдың син.
Җаныңа гасырлар сыйган
Дәвер-китап булдың син.

## *Булмый бит...*

Ачуланган чаклар була,
Үпкәләгән чакларың.
Шул мәлләрдән күңелемдә
Әллә күпме тапларым...

Көнләшкән мизгелләр күпме,—
Көн күрсәтмәгән чаклар.
Без әйтерсең мәңге юлчы,—
Юлларда чатлар, ятлар.

Башка очрашмабыз, диеп,
Аерылып киткән юллар,
Сезгә башка язмыш юк, дип,
Кире кайтарган еллар...

Ачуланып йә көнләшеп,
Аерылмыйк инде башка.
Гомер — бер, ике итәм дип,
Бәреп булмый бит ташка.

* * *

Мәхәббәткә ышандырып,
Мине шундый ярattылар:
Ярларымнан ашкач ташкын —
Бар дөньяга тараттылар.

Ә мәхәббәт шундый «кызык»:
Яратсаң — бар, таратсаң — юк...

## *Ярар ла ул...*

Ярар, кит син, кит башкага,
Башкага китим мин дә.
Сине миңа китерәм, дип
Вәгъдә бирә ай көн дә.

Яңа тапкан ярың чибәр,—
Бәгърем, кайтарып җибәр!
Йөрәккәең барыбер бит
«Нәҗибәм!» диеп тибәр.

Читләшер сөйгән ярың,
Белгәч Нәҗибәң барын.
Ул чакта кемгә салырсың
Җанга сыймаган зарың?

Яңа ярлар бардыр ул,
Яраттыралардыр ул.
Сагышларны вакытлыча
Тараттыралардыр ул...

Ә вакыт — гомермени?—
Чын сөю кимермени?

## *Булмый*

Без барыбер
Аерылмабыз, диден.
Очраштырыр дөнья —
Тар бит ул.
Өермәләр сине
Алып китте —
Чын мәхәббәт җирдә
Бар бит ул.
Каерылсак та,
Кушылырбыз, диден.
Очар өчен канат
Пар бит ул.
Ташкыннары сине
Алып китте.
Елгаларның яры
Бар бит ул.

Аерылсак та,
каерылсак та диден,
Кабат кайтачакбыз
Үз-үзебезгә.
Әмма ул чак
шундый авыр булыр
Бер-беребезнең карау
Күзебезгә.
Ә дөнья тар,
Ә сөю бар.
Үз-үзеңнән
Качып булмый!
Һәм күзләрне
Ачып булмый.

## *Сөю? Чәчкә — чәч!*

Сөю юк!
Бу синең өчен
Күптән хакыйкать икән.
Синме сөюне, әллә ул
Синеме ташлап киткән.

Үзең җыр язган буласың:
«Мәхәббәт — бөек икән».
Синең буй җитә алмаслык
Мәхәббәт биек икән.

Үрелмә,
Яна кулларың!
Җан белән үрелмәгәч,
Сүтелә, таркала сөю,
Чәчкә чәч үрелмәгәч.

Сөю юк!
Минем өчен дә
Хакыйкать инде ачык.
Чәчкә чәч үрелсен өчен
Башта чәч кирәк, гашыйк!

* * *

> Мәхәббәт юлы үргә,
> Хәтта илтсә дә гүргә.

Син миңа һәрвакыт, сөю,
Хәвефле чакта килдең.
Мин елаганда елмайдың,
Мин елаганда көлдең.

Кояшым сүнгән чагымда
Килдең үчекләп, көлеп.
Канатым сынган чагында
Очар кош булып, җилеп.

Уйсыз чагымда уй булып,
Моңсыз калсам, җыр булып.
Җаным бушап калган чакта
Җан тирмәмә нур булып.

Һәрчак көтмәгәндә килдең.
Каршы да алалмадым.
Шыр ачык, йозаксыз җаным —
Саклап та калалмадым.

Миннән сиңа, синнән җилгә,
Җилдән күчте җирләргә.
Җилләр, сулар кабер казый
Мәхәббәтем җирләргә.

Туган-үскән җирләргә.

* * *

Синнән миңа берни кирәк түгел,
Тик язларны кайтар!
Син киттең дә, минем күңелемдә
Калды бары аһ-зар.

Аһ-зарларны айга салыйм, дисәм,
Урлагансың икән.
Кереп яныйм, дисәм, кояшны да
Куймагансың икән.

Тоташ төннәр... айсыз, йолдызсызлар...
Аһ, йөрәгем, дисәм,
Күкрәгемдә тере кузлар гына —
Йөрәгем дә киткән.

Бәхет шушы икән.

## *Әллә нинди җыр бу*

Ул күзләрне күрми яши алмыйм,
Ул сөюсез типмәс йөрәгем.
Төнге албастыга рәхмәт укыйм
Күрсәткәнгә аның өрәген.

Әллә нинди җыр бу бер ахырсыз.
Әллә ничек авыр, бик авыр.
Шушы авырлыктан мәхрүм калсам,
Җансыз гәүдәм кара җиргә авар.

## *Ник кагылдың син, ә?*

Үзгәрдеме әллә синең белән
Көне йә төннәре?
Агачларда бөре урынына
Сагыш төеннәре.

Былтыргыдан бөре килеш калган
Хисләр иде миндә.
Сары көзең, ак бураның белән
Ник кагылдың син, ә?

Мин чын сөю көтеп көзгә җиттем —
Яфрак яра идем...
Сөю үзе килеп кагылганчы
Барыбер бара идем.

Көзен яфрак яра идем әле
Барысына үч итеп.
Чәчәк булып тамар иде карга
Йөрәгем тып итеп.

Үзгәрдеме дөнья сине тапкач?
Үзгәрдеме һава?
Көзен сары яфрак, ә кышларын
Һаман ак кар ява.

Үзгәрде...
бу дөнья көзгә кергәч...
Сөю
көзе белән күзгә кергәч...

## *Ә нигә?*

Бу — синеке, бу — минеке,—
Аерабыз һаман да.
Язмышларны аңлау кая —
Канатың каерганда...
Шулай кирәк, дип түзәбез,
Түзәбез, өзеләбез...
Үткәннәргә күзне йомып,
Яңадан «төзеләбез».
«Төзеләбез», өзеләбез...
Шул ук җан җөйле-җөйле.
Дөньясы шулай рәхимсез,
Көйләми безнең көйне.
Ә безнең көй — нинди көй бит!
Сыгылып чыга җирдән...
Менә мин дә аерылдым
Гыйффәтем алган ирдән.
Ә безнең көй — шундый көй бит!
Сыгылып чыккан җаннан.
Ә балабыз тамчы-тамчы
Яралган безнең каннан...
Бу — синеке, бу — минеке,—
Аерып кара аны!
...Баласын яралткан ирдә
Кала хатыннар җаны.
Бу — синеке, бу — минеке,—
Җаннарны аерабыз.
Өзелсә дә җан, түзәбез
Бер мәлгә җансыз да без.
Ә нигә?!

## *Әгәр дә уйлаганда*

Күзгә күндә күлгән булдың,
Хәтта күк елаганда.
Уйсыз булып кына түзәм,
Әгәр дә уйлаганда...

Ябык калыр иде хәтта
Язын тулган бөреләр.
Таммас иде ләйсән яңгыр,
Җилләр елап йөрер лә.

Ярый әле, белмәгәннәр
Язлар, җилләр, бөреләр.
Соңгы карлар әкрен генә
Җиргә төшеп эриләр.

Әллә язгы ташкыннарга
Кушылып агыйм микән?
Хыянәтне белми торган
Башканы табыйм микән?

Ул, бәлки, мине яратыр,
Ә мин сине яратам.
Икәү бергә йөргән юллар
Ак калсын дип, кар атам...

Ә эзләргә сагыш ята —
Гүя яз булмаган да.
Уйсыз булып кына түзәм,
Әгәр дә уйлаганда...

## *Яфрак булыр көннәр бар...*

Беркемнән дә
сорап-нитеп тормый —
Ява яңгыр, дулый
бураны.
Беркемнән дә
сорап-нитеп тормый —
Килеп керә җанга
уйлары.

Уйлар бураныннан
җанда кышмы?
Чигәләрдә ап-ак
кармы соң?
Чигә карларымны
эретердәй
Җылы куллы кешем
бармы соң?

Уйландыра уйлар
буранынnan,
Уелам да китәм
ялгызым.
Мин бит ташып килгән
мәхәббәтне
Язгы ташкыннарда
агыздым.

Һәм ул күптән инде
башка ярда.
Мин дә үз ярымда
түгелмен.

Сабырлыкны сагышларга
саплап,
Саргайдым да менә
түгелдем.

Юк, сагыштан түгел
саргаюым.
Яфракларның беләм
күзләрен.
Бөреләрнең йөрәгенә
кача
Сөю салган ялкын
эзләре...

Уйландыра. Сары
бураннарга
Салып китәм уйны
күзләрдә.
Сары яфрак җиргә
төшкән саен
Өзелергә, ләкин
түзәргә...

Беркемнән дә
сорап-нитеп тормый
Ява җанга сары
бураннар.
Яфрак булыр көнне
уйлый-уйлый
Атлап барам күзге
урамнан...

## *Егет җыры*

Әллә каян килеп кердең
Кояшлы балачакка.
Җитен толымнарың сибеп,
Йөгердең кайсы якка?

Әйләнеп карамадың,
Әйләнеп карамадың.
Йомшак җитен чәчләреңне
Күрдем җил тараганын.

Толымнарың белән җанга
Юллар салгансың икән.
Шул юллардан яшьлегемә
Кереп калгансың икән.

Әйләнеп кара әле,
Әйләнеп кара әле.
Күңелемдә һаман да син,
Син салган яра әле.

Толымнарың инде хәзер
Җитен түгел, кар икән.
Тагын очрашты карашлар —
Чын мәхәббәт бар икән.

Әйләнеп кара әле,
Әйләнеп кара әле.
Мәхәббәтем шул юл буйлап
Һаман да бара әле...

# *Мираж*

Сөйгәнемне дә беләсең,
Син үзең дә сөясең.
Хисләреңнең ташкыннарын
Тыя алмый киләсең.

Хисләреңне тыңлап тордым:
Нигә алар тышаулы?
Алыштырып булмыйдыр шул
Чын сөю һәм сусауны...

Бу ни?
            Уйлар туктап калган?
Төн уртасы —
                        бак күккә!
Салават күпере янган?
Йөрәкләрдән-йөрәкләргә
Күпер ич бәхеткә.

Тагы кара...
                    юк,
                        беткән...

## *Үпкәләшкәч*

Башка бер дә авыр сүзләр
Әйтмәм сиңа, кадерлем.
Бәргәләнгән, өзгәләнгән
Көннәре бу бәгырьнең.

Әрнеп кычкырырдай мәлдә
Әгәр булсаң янымда,
Күз яше аша елмаеп
Дәшәр идем тагын да.

Бәргәләнә, өзгәләнә
Үзәкләре бәгырьнең...
...Башка бер дә авыр сүзләр
Әйтмәм сиңа, кадерлем.

* * *

Яратасыңмы — ярат.
Дөньяга гайбәт тарат.
Китәр юлыма инде
Җигеп куелган пар ат.

Ул пар атта син кучер —
Минем хакта соңгы җыр.

## *Ничек ышаныйм?*

Ышандым язларны синең
Йөрәк ялкының диеп.
Каршыларга чыктым аны
Бәйрәм күлмәгем киеп.

Ышандым назлы җилләрне
Синең сулышың диеп.
Башларымны юләр иттем
Җилләргә кушылып биеп.

Кояш чыкмас дип уйладым,
Таңда син уянмасаң.
Онытырсың дип уйладым,
Әгәр мин уйламасам.

Һәм... син киттең.
Шашып-ташып
Килә дә китә язлар.
Җилләр исә, җанны кисә.
Җилләр кемнәрне...
назлар?..
Көн дә таңда басып җанга
Калка да чыга кояш.
Нидән шулкадәрле ачы,
Күзләрне өтә бу яшь?
Яз, кояш, җил — юк, син түгел.
Аларына ышандым.
Үзем үзем түгеленә,
Әйт соң,
Ничек ышаныйм?

## *Юктыр... юктыр...*

Синнән башка яшәү юктыр миңа,
Юктыр миңа яшәү, кадерлем!
Синнән башка миңа кадерлерәк
Кара төне салкын кабернең.

Ә шулай да синнән качып барам.
Тоташ томан ята арага.
Ярый әле, синең рәсемең бар
Еллар көзгесендә карарга.

Еллар ни дә, юллар нәрсә соң ул?
Мосафир җил кага капканы...
Шундый тирән җиргә яшерелгән
Безнең мәхәббәтне тапканмы?

Тагы челтерәп китә элмәкләре.
Күңел капкам тагы шыр ачык.
Кояшыннан куркып баткан айдай,
Үз-үземнән барам мин качып.

Үз-үземнән качып кына түгел,
Ташкын булып ташып барам мин.
Җыр дәрьясы белән тоташтырам
Ярны ярдан эткән араны.

Җырдан башка яшәү юктыр миңа?
Юктыр миңа яшьнәү, кадерлем!
Сөю белән җырым аша белдем
Җирдә яшәүнең дә кадерен.

## *Ялгыз калдым*

Ялгыз калдым.
Көтеп алдым мине сөйгән,
Миңа гына табынганны.
Язмышымда ялгыш гына
табылганны.

Күңелемнән качты болыт.
Булдым кояш,
Җылы яңгыр булып яуды
Шатлыктан яшь.
Кочакладым. Үптем...
шаштым.
Һәм бераздан аннан
качтым.
Фани җирдән
Эзләп йөрим мин фәрештә.
Үрнәк булсын,
Ут уйнатсын ул һәр эштә.

Җирдән тапмадым
фәрештә.
Күктәгеләре дә эштә.
Сөю, сагыну дигән хисне
Аңламыйлар һич тә...

## *Пар аккошлар арасында*

Ташла да кит әйтми-нитми генә,
Ялган назлар миңа тимәсен.
Суын түгеп, ялгызым да ишәм
Язмышымның ярык көймәсен.

Диңгезләргә таба омтылгандай,
Мәңгелек яр эзләп туктaлам.
Үз ярымны тапмый укталудан
Мин туктамам сыман, туктамам.

Хыялымда моңсу күл өсләре...
Төнбоеклар чәчәк аталар.
Дулкыннарда һаман толым чайкый
Яшел камыш, зифа ак таллар.

Күңел күгем өсләрендә йөзә
Ак аккошлар, кара аккошлар.
Күңелемнең төпләрендә йөзгән
Үземнән дә яшерен аккош бар.

...Ташла да кит, әйтми-нитми генә —
Ялган назлар миңа тимәсен.
Пар аккошлар арасында булсын
Язмышымның ялгыз көймәсе.

## *Мәхәббәткә күз йому*

Очрашабыз, хушлашабыз,
Аерылышып китәбез.
Китәбез дә, тагы шулай
Очрашуны көтәбез.

Юкса, бар бит, бар бит инде
Аралашу чарасы.
Хатлар бара, якын, дәшсәң,
Телефоннар арасы.

Әмма ләм-мим без дәшмибез,
Чөнки юк әйтер сүзләр.
Китәбез дә көтәбез без —
Кайчан очрашыр күзләр.

Шулкадәрле мәхәббәтне
Сер итеп саклыйбыз бит.
Бер-беребезгә сиздермәүне
Ничектер аклыйбыз бит.

Без аклыйбыз, ә мәхәббәт
Булалмый икейөзле.
Берчак җанны ярачак та
Ачачак әле күзне.
Фаш итәчәк ул безне.

## *Ди-ва-на!*

Бүген тагы син төшемә кердең:
Син яшь идең,
Мин дә яшь идем.
Мин тагы да киттем
сине ташлап.
«Китмә»,— диеп
Хет бер дәш идең...

Кайтыр идем кебек,
кайтыр идем,
Син дәш идең...
Их, мин яшь идем!
Инде гомер буе
менә шулай
Төшләр генә күреп
яшимен.
Кояш көлә, җилләр
әй уфтана.
Яфрак сөйли,
Чаган уйлана:
«Мәхәббәттән китү —
Ул кәүсәңне
Ташлап китүдер бит,
Ди-ва-на!»...

## *Кыя карагае*

Зәңгәр упкын. Мәгъруp кыя.
Кыя ташта карагай.
Сикермәкче була ярдан,
Кыя тота — ярамый.

Дулкын юа. Карагайның
Ачыла тамырлары.
Таш ярып табылган туфрак —
И, белә кадерләрен.

Диңгез җиле карагайның
Ябышкан якасына.
Ышангандай карагайның
Алышта ятасына.

Сынмады тирәк, тик кыя
Ярылды көчле валдан.
Җирен кочкан килеш нарат
Зәңгәр диңгезгә ауган.

Ташламады туган җирен,
Аңа таш суты кирәк.
Туган җирсез үзе булып
Калганнар, беләм, сирәк.

## *Җилгә сал... салма...*

Көн саен уйлыйсың микән
Син һаман минем хакта?
Таңнарда озатасыңдыр
Сәламнәр минем якка.

Көн саен уйлыйсың микән
Син һаман минем хакта?
Хисләреңне саласыңдыр
Һаман кәгазьгә — акка.

Тик шулай ит, тик җилләргә
Салмачы хисләреңне.
Мине килеп табып, алар
Алмасын исләремне.

Җилгә сал хисләреңне...

## *Төшләр...*

Төшләр...
Искәртеп торалар:
Сөю калган үткәндә.
Тирәнәя бара яра,
Сөю ясап киткәнгә.

Төшләр...
Кабатлап торалар:
Кабатлама хатаны,
Чын булса, сөю югалмый,
Эзлә, эзлә, тап аны.

Төшләр...
Юатып торалар:
Табылыр, елама, дип,
Үткәннәргә хатлар бармый,
Хатларың юллама, дип.

Төшләрне
Тыңламый хисләр.
Кабатлый хаталарны.
Үткәннәргә хатлар язам,
Табачак хат ул ярны.

Төшләрдә
Хаклык бар барын.
Чын мәхәббәт югалмый.
Язны үзең яса икән,
Язсыз ташкын юл алмый.

Ә без
Күзләргә керәбез.
Язда кызыл алма юк.
Күкләргә аша күңелләр,
Имеш, җирдә Алла юк.

Төшләрдә
Алма бирәсең.
Алмалар пешкән дә бит,
Алма исләрен китерә
Җилләре искәндә тик.

## *Сагыну*

Башларымны кайнар күкрәгеңә
Салыр идем, бәгъре*м*.
Хисләремне хисләреңә кушып,
Кабыныр идем, Тәңрем...

Уйларымны уйларыңа салып,
Уелып китәм ялгыз.
Йөрәгемнән ташкан хисләремне
Дәрьяларга салыгыз!

Суда батмас, утта янмас хис ул —
Кайнап чыгар дәрья.
Мәхәббәтне мөмкин йөгәнләргә
Бары икәү бергә.

Башларымны кайнар күкрәгеңә
Куяр идем — кайда?
Җылы эзләп тәрәзәгә килгән
Җаны туңган ай да...



# *ТӨН — МИНЕКЕ*

*Саумы, төн, айсыз, йолдызсыз,*
*...Җилсез һәм яңгырсыз төн!*
*Җанымны тыңларга бер мәл*
*Мөмкинлек бирәсең син.*



## *Әгәр белсә...*

Минем хәлне балык күрсә,
Күлен миңа бирер иде.
Ул, аңласа, суга керми,
Утка үзе керер иде.

Минем хәлне кошлар күрсә,
Канатларын ташлар иде.
Миңа биреп канатларын,
Җәяү йөри башлар иде.

Минем хәлне тик син генә
Күреп тордың — җаның сукыр.
Тик син салган яраларны
Бер тотлыкмый сукыр укыр.

Балык, кошлар минем хәлне,
Минем хәлне белми әле.
Аңлар иде Мәҗнүн үзе,
Синнән алай булмый әле,
Синнән булмый...

* * *

Язмышыма яр кирәк,
Күңел ярыма — терәк;
Сискәндем, һушсыз калдым:
«Ул — мин», — ди ямьсез өрәк...

Хәзер ярлар кирәкми:
Өрәк ярды йөрәкне.
Һәм...
Мин ике йөрәкле...

* * *

Саумы төн, айсыз, йолдызсыз,
Җилсез һәм яңгырсыз төн!
Җанымны тыңларга бер мәл
Мөмкинлек бирәсең син.

Яфрак та селкенмәс төн — син,
Ә йөрәкләр талпына,
Яфрак кадәр йөрәкләрнең
Мәхәббәте хакына.

Бер йолдызсыз кап-кара төн,
Гашыйклар йолдыз таба.
Йолдызлардан җыела-җыела
Сөю кояшы бага.

Әй мәхәббәт, акны кара,
Караны ак итәсең.
Мәңгелеккә күчергәндә
Мизгеллек җил икәнсең.

## *Тик бер атна...*

Тик бер атна сине күрми тордым,—
Кешеләрсез калды җир йөзе.
Өнсез, телсез калды бар дөньясы,
Ишетелә бары җил сүзе.

Син аларны миңа юллагансың,
Чәчләреннән сыйпа, җил, диеп.
Сагынуларым башларымнан ашты,
Шатлыкларын урлап кил, диеп.

Мин аларны кире юлламадым.
Мин аларга үзем тотындым.
Сиңа алып бармадылар җилләр,
Җаным җилләр белән тутырдым.

Тик бер атна синең сулыш булып,
Уфлап йөрде җилләр җанымда.
Тик бер атна, синсез тагын бер көн,—
Җилләр түгел, давыл таңымда.

Син җибәрдеңмени тагын да
Җаның давыллаган чагында...

* * *

Көтмәгәндә яңгыр явып үтте,
Чәчләремне лычма чылатып.
Сөю килгән булды көтмәгәндә,
Бар җанымны китте кузгатып.

Кар-бураны тузды — көттеммени,
Юллар шулай, диеп, ябылыр.
Әй, сатлык җил, кемгә пышылдыйсың,
Табылыр ул, диеп, табылыр?

Яңгыр явар, кубар давылы да,
Кар-бураннар тузар, тузачак.
Аннан башка гына узар гомер,
Узма, дисәң дә бит, узачак.

## *Беренче һәм соңгы*

Әкиятләрнең ахыры әйбәт була.
Мәхәббәтнең — була фаҗига.
Язмышыңны кара, дигән сыман,
Әкрен генә шуып ай чыга.

Минем мәхәббәтем авыр, зур ул.
Сыйдыралмый әллә йөрәгең?
Тик югалткач кына аңларсың син
Минем мәхәббәтнең кимәлен.

Тик соң булыр, кояш, ай шикелле
Урап-урап йөрмәм, белеп тор.
Минем сөю сиңа беренче һәм
Соңгы тапкыр яңгыраган җыр.

# *Яфрак — язмыш*

Син — кәүсәсе, мин — яфрагы агачның.
Бер-береңнән башка яшәп кара син.

Мин туктаусыз лепер-лепер киләм,
Ә син мине тотып торасың.
Телгә бетеп, онытылган чакта
Җилнең уңаена борасың.

Син ныграк миннән, сизеп торам.
Олпатрак күрер күзгә дә.
Мин өзелсәм, тагы күпме яфрак,
Сусамассың әйтер сүзгә дә.

Әмма минсез сиңа авыр булыр,
Һәрбер яфрак бары бер генә.
Агачыңнан өзелеп, һәрбер көздә
Ләхетләргә шулай кер менә...

Синең өчен шулай ничә үлеп,
Шулай ничә тапкыр терелдем.
Синең өчен ничә туфрак булдым,
Ничә шушы җирдән сөрелдем.

Ә башкалар ел да кайтты микән,
Җыела алды микән кабаттан?
Мин ләхеттән кабат кайтып киләм,—
Син киләсең чыгып кабактан...

## *Төн — минеке!*

Төн — минеке!
Йоклап ятканнардан
Рәхәтләнеп көлеп йөри ай:
Күпме югалтасыз, әй, кешеләр!
Нинди мәхәббәтне, ай-яй-яй!

Төн — минеке!
Йоклап ятканнарның
Тәрәзләрен кагып китә җил:
Күрми каласыз бит, әй, кешеләр!
Нинди хәрәкәттә дөнья гел.

Төн — минеке!
Йоклап ятканнарга
Челтер-челтер дәшә сулары:
Без китәбез, күрми каласыз бит,
Хушлашасы иде — шул бары.

Төн — минеке!
Йокы кирәк түгел!
Йокысызлар, йөрәк кирәкме?
Айга, җилгә, агымсуга салып
Мин чайкыймын төнге йөрәкне...

## *Ә ай белеп көлә...*

Шатлыкларыңны ал кире,
Кирәкми миңа бүтән.
Миңа елмаер кояшым
Күгемне ташлап киткән.

...Син киттең. Мин үзем кудым.
Ялгыз каласым килде.
...Син киттең. Калдым ялгызым,
Аем кычкырып көлде.

Чөнки белгән шул ялгыз ай,
Ах, ничек әле белгән!
Айның бит шундый холкыннан
Япа-ялгызлык килгән.

Айның берүзенә бер күк.
Берүзенә кара төн.
Әйе, ай белеп көлә ул
Ялгыз калу халәтен.

## *Йә йоклама, йә уянма...*

Төшләремә киләсең дә
Шакыйсың ишегемне.
Инде әйтмим, керетмим, дип,
Соң, диеп, кичегелде.

Ашыгып ачам ишекне,
Аламын кочагыма.
Гүя тәүге кочаклашу—
Кайтамын кыз чагыма.

Күзләреңнән назлар эчәм,
Сеңәмен күкрәгеңә.
Төш кенә бит: гаҗиз калам
Сөюнең күкрәвенә.

Иң авыры уяну шул.
Чын сөю төштә генә.
Йә йоклама, йә уянма —
Бу хәлгә төшмә генә.

## *Зәңгәр юрган*

Җәй иде бит,
Нидән өшедек без? —
Юрган эзләп киттек ябынырга.
Җаныбызда әллә сүнгән булган
Сөю дигән учак, табынырга?

Көз иде бит,
Инде аерылдык,
Башкаларга киттек яр булырга.
Агачларда сары яфраклар тик
Пышылдашып калды: «Зар булырга...»

Кыш иде бит...
Нигә ябынмыйбыз
Шуып төшкән зәңгәр юрганны без?
Ничек җиңел генә җимергәнбез
Сөю кадәр сөю корганны без...
...Читтә ята
Зәңгәр боздан сырган юрганыбыз.

## *Аңлашу*

Төн уртасы.
Тик бер ак ай
Башын салыр
Урын тапмый.

— Кочма...
Әнә, ай оялып
Битен болыт
Белән каплый.

— Юк, булмасны
Таләп итмә.
Кочагымнан
Чыгып китмә.

— Йә, таң ата.
Ай югалды.
Ай урынын
Кояш алды.

— Үпмә, әнә,
Оялды да
Кояш бите
Алсуланды.

— Юк, булмасны
Син сорама.
Кояш түгел,
Ул зур алма.

— Алма булса,
Алып бирче!

— Ах, сихерче!..

## *Яшенле мәхәббәт*

### I

Сукыр кура — кем дә булмас...
Кердем ташландык йортка.
Ялт итте яшен яктысы.
Аһ, уйлаганмын — юкка...

Синең йөзгә, күзләреңә
Мин карап тордым шашып.
«Юлаучы йә угрымы ул,
Кергән яшеннән качып?»

Килә-китә яуды яңгыр.
Сукыр йортта сукыр төн.
Күпме еллар төн яшергән
Йортка шәм кабыздың син.

Шәм янына икебез дә
Килдек без якынрак.
Шатлыгыннан елый-елый
Янды шәм балкыбрак.

### II

Шәм яктысы. Син дә миңа
Карап тордың уйчан гына.
Таң алдыннан кочагыңнан
Чыгып киттем — кыз чагымнан.

Чалт аяз көн. Елый-елый
Сүнеп барган шәмнән түгел,
Без кояштан, көннән качтык...
Сукыр йортның күзен ачтык.

## *Яңа ялгызлык*

Түгелә моң,
Сибелә бию көе,—
Бөтерелеп кызлар бииләр.
Урам көйләренә ярсу өстәп,
Кушылалар җырга хөр ирләр.

Тыпыр-тыпыр
Аяк тавышлары
Инде тынды, тынды баяны.
Ялгыз калгач, ниләр эшләр алар,—
Сагынырлармы шау-шу баяны?

Түгелде моң,
Терпелдәде җаннар.
Ялгыз калды чая толы да.
Яңа елда сиңа бүләгем, дип,
Берәү биргән хушбуй кулында.

«Хуш киләсең,—
Диде,—Яңа елым!»
Һәм шешәне ташка ташлады.
Яңа елда яңа ялгызлыгы
Белән кабат яши башлады.

## *Синең күзләр*

Көзнең сары яфрак яңгырыдай
Түгел әле, сагыш, җанымнан!
Сагышлардан бераз бушап калсам,
Мәхәббәткә шулай ялынмам.

Кышның ап-ак бураннары кебек
Ак җилләргә салыйм уйларны.
Юк та диеп белим дөньялыкта
Була алмый калган туйларны.

Язның ярсу ташкыннары булып
Ник кайтасыз, хисләр, тагын да?
Мәхәббәтне инкарь итеп кара
Дөнья чәчәк аткан чагында.

Көзнең сары арышларын чабып,
Эскерт-эскерт өям җаныма.
Зәңгәр гөлләр кереп оялаган
Сары сагышларга, йа Хода...

Синең күзләр...

## *Мин — мәхәббәт*

Мин — мәхәббәт, минем сөю
Кышның карын ташкын итә.
Мин — мәхәббәт, минем сөю
Көткәнеңне якынайта.
Мин — мәхәббәт, минем сөю
Бөреләрдән яфрак сүтә.
Мин — мәхәббәт, йөрәгеңдә
Яңа дөнья тәшкил итәм.
Мин — мәхәббәт, мин — хәрәкәт,
Мин булмасам, бар һәлакәт.
Мин — мәхәббәт, мин югалсам,
Кеше күңеле тик җәрәхәт.
Мин — мәхәббәт, кояшны да
Кешеләргә күчерәмен.
Мин — мәхәббәт, кешеләргә
Наз чишмәсе эчерәмен.
Мин — мәхәббәт, мин — иң зур ат.
Мин — иң зур көч, миңа каршы
Тора алмый бер яманат.
Мин — мәхәббәт, мин — тереклек.
Бар хисләргә тик мин җирлек.
Бу дөньяда мәхәббәттән
Гүзәллек һәм мәгърур ирлек.
Мин — мәхәббәт, ак кар булып
Бар дөньяны йөрим аклап.
Мин — мәхәббәт, бар дөньяда
Яшәешне йөрим яклап.
Мин — мәхәббәт, кагылдыммы,
Таш күңелне эретәмен.
Кешеләргә мәңгелеккә
Бару юлын өйрәтәмен.

Мин — мәхәббәт, мин һәркемдә.
Мин мәңгелек йөрәгеңдә.

## *Сиңа да, миңа да*

Тәрәзәмнән кап-кара төн карый,—
Пешәлмәгән миләш.
Тәрәзәмнән мин дә төнгә карыйм,—
Төшәлмәгән кәләш...

Син дә карыйсың бит тәрәзәңнән,
Сиңа да карый төн.
Күрмәмешкә салынып сөйләшәсең
Алма белән тик син.

Мин дә төннең аен гына күрәм,
Ул да алма кебек түгәрәк.
Салкын айга кереп көярмен, дип
Уйламаган бу җан-күбәләк.

Якын булгач, өздең алманы син,
Айны өзалмадың...
Ир булсаң да, үксеп еладың бит,
Ахры, түзалмадың.

Таң атуга төн дә китеп барды,
Син тешләгән ай да югалды.
Күңел канатларын сыгып төшкән
Әче алма булып уй калды.

## *Beləбез бит*

Ул безнең җыр, безнең бию көе,
Ул безнең моң, безнең бию иде.
Мин, чәчәккә кунган күбәләктәй,
Башларымны җуеп бии идем...
Иңнәреңдә син тибрәтә идең —
Сөю диңгезенең дулкынында...
Минем кебек рәхәт кичмәгәндер
Оҗмах түрендәге хур кызы да.

Ул җыр гүя белеп өзгәләнде
Җирнең синсез-минсез әйләнгәнен.
Сизмәгәнбез җыр зынҗыры белән
Язмышларның мәңге бәйләнгәнен.

Синең минем җанда,
Минем синең җанда
Беләбез бит һаман әйләнгәнен.

## *Булмый*

Күз яшьләрем ачы-ачы.
Тама алар тамчы-тамчы.
Тамчы, тамчы, тамчы, тамчы,
Безнең арабызга тамчы!

Тамчы-тамчы яшем булып
Минем җаным ката бара.
Тирәнәя бара яра,
Ераклаша бара ара...

Синнән миңа, миннән сиңа,
Карап торсаң, ара юк күк.
Канап торган яра юк күк.
Күреп тора бары бер күк:
Ачы тауны үтеп булмый.
Җан ташларын сүтеп булмый...
Дәрья кибеп, тау күчсә дә,
Үз-үзеңнән китеп булмый.

## *Әле син белмисең...*

Гаҗиз калдым:
Бүләк итеп,
Китергәнсең ылыс.
Йөрәгемә кадалды ул
Булып үткен кылыч.

Ни уйладың?
Аңлый алмыйм:
Һәм шул көннән бирле
Аяк өсте табут кидем,—
Салкын гүр күк җире...

Ә монысы төш:
Табут, ылыс.
Табутта кем дисең?
...Мәхәббәтне җирләп булганлыкны
Әле син белмисең...

* * *

Җир кадәрле авыр икән сөю.
Ләкин тора үзе күчәрендә.
Әйләндерү өчен дүрт кыйблага
Җитми икән ялгыз көчләрең дә.

Дүрт кул кирәк икән тоту өчен,
Ике йөрәк кирәк кузгатырга.
Тыпырчынам — селкенми дә күчәр.
Һаман дан җырлыйлар кыз-батырга.

Җир кадәрле авыр икән сөю,
Җыр кадәрле моңлы, михнәтле.
Кеше гомере генә җитмидер шул
Аңлар өчен шундый хикмәтне.

Әй тырыштым булсын, диеп сөю.
Сөю булсын диеп — күпме көю...
Күчәр инде әйләнеп тә китте —
Дөньясыннан китәр вакыт җитте.

## *Таштай бөре дә ачыла*

Кайтавазлар — ят авазлар.
Күктә түгел, түгел айда.
Менә шулай үч иткәнгә,
Сүнәсез сез әллә кайда.

Юкса, алар яз китергән,
Бөре-бөре наз китергән.
Бөре саен сөю сүзе,
Һәрбер бөре — аның күзе.

Бөреләре чишелергә,
Түгелергә тора хисләр.
Ул хисләрдә таш бөредән
Яфрак ясар олы көч бар.

Йөрәк кайчак таштайката.
Һәм бөре хәленә кайта.
Ачылып җанны эретә
Һәм...
Сөю исемен йөртә.

## *Без бергә генә юк...*

Күпме көттек очрашуны —
Очраштык та хушлаштык.
Киткән чакта әйтер өчен
Тик бердәнбер сүз таптык.

«Хуш!» — бары тик бердәнбер сүз,
Карап торды күпме күз.
Ничә тапкыр кабатладың:
Берни әйтмә, әйтмә — түз!

Күпме көттек очрашуны —
Көтмәскә булган да бит.
Дөнья — юк, без икәү генә, дип,
Китмәскә булган да бит.

Хәзер без икәү генә юк.
Дөнья бар, гел булачак.
Бу дөнья берчак, мөгаен,
Сак-Сок белән тулачак...

* * *

Елга ташы — мунча ташы,
Йөзек ташы — асыл таш.
Мунча ташының эченнән
Энҗе чыкты — ярылгач...

## *Сәер сөенеч*

Сине миннән, мине синнән
аерыр көч бар — үлем.
Синсез җанда сулып бара
зәңгәр мәхәббәт гөлем.

Ярларны да бер-береннән
аеру озак түгел.
Яра ясап, бары кирәк
агымсуларын түгү.

Безнең җаннар агымсуы
сөю генә, беләсең.
Дөнья — ялган. Һәм син анда
белә-белә бөләсең.

Икебезне мәңгелеккә
кавыштырыр көч — үлем.
Үлгәнемә сөенәмен —
барыбер җаныма килдең.

## *Мин генә...*

Мин сине яраткан кадәр
Яратсаң әгәр мине,
Таулар тез чүгәрләр иде,—
Яратмадың син мине.

Әгәр мин яраткан кадәр
Ярата калсаң мине,
Ай акылдан шашар иде,—
Яраталмадың мине.

Әгәр минем яратуның
Тамчысы булса синдә,
Җилләр тынып калыр иде,—
Исмичә бу мизгелдә...

Ярый, яратмадың әле—
Ае да көндәгечә.
Таулар горур карап тора,
Сызгырып җилләр исә.

Мин генә сөю алдында
Тезләнгән тау, шашкан ай.
Сөю тотып торган давыл,
Тоткындагы ташкындай.

## *Ничек үпкәләттем икән?..*

Китмәкче булдым синнән,—
Яшәргә калды төннәр.
Китмәкче булдым синнән,—
Җанымда калды кемнәр?

Төннең кара чәчәкләре,
Сагышлары үткәннең.
Иреннәремне пешерә
Әллә кайчан үпкәнең.

Көтмәкче булдым сине,—
Һаман шул бер ай инде
Синең карашларың белән
Тәрәздән карап көлде.

Пәрдәләр белән томалап,
Керетмим айның нурын.
Булмасын әле сагышка
Минем күңелдә урын.

Үпкәләде дә, их, китте,
Күгемнән качты аем.
Ничек үпкәләттем икән,—
Гомер кояшым байый...

# *Ул чакта да...*

Ялгыз калгач, уйланасың:
Кемнәрне югалттым мин?
Күңелемне вакытлыча
Ни белән юаттым мин?

Кемнәрне югалттым да мин,
Кемнәрне юаталдым?
Кемнәрнең күңелләреннән
Күңелемә ут алдым?

Бергә чакта уйланмаган,
Гел бергә булыр төсле.
Ялгыз калгач, уйлар кискен,
Ялгыз калгач, уй көчле.

Шатлыклар шашып шакыйлар,
Куышып килә кайгы.
Тәрәзәдән тотып алдым
Сагыштан тулган айны.

Күңел тәрәзәләремнән
Әй, ялгыз ай, ник кердең?
Өермә купты күңелдә,
Очы качты фикернең...

Ул чакта да аны көттем —
Тәрәзәмә син килдең.
Ул чакта да ул килмәде —
Мин еладым, син көлдең.

Елатып китә белгәннәр
Юатмаганнар мине.
Юатканнар елатмаган
Һәм тапмаганнар мине.

## *Гөнаһ алмасы*

Ялгыз калгач ишетелә
Уйларның тавышы да.
Йолдызлар четердәп яна
Ак айның сагышында.

Боз тотмак сулар агышын —
Андый хәл буламыни?
Күңелгә уй, диңгезгә су
Акмыйча туламыни?

Яңгырны салкын тотмакчы
Күгеннән төшермичә.
Кырау сукмакчы алманы
Кызартмый, пешермичә.

Ай ялгыша, күк йөзендә
Йолдызлар арта гына.
Диңгез суны, күңел уйны
Туктаусыз тарта гына.

Кызарып пешкән алмалар
Өзелеп төшә җиргә.
Кырау суксын алмаларын,
Ашап булмагач бергә...

Кагылма, кырау, алмага!
Барыбер ашарбыз бергә!
Гөнаһ алмамны үзәм дә
Алып керәмен гүргә...

## *Йөрәктә май бураны*

Май ае ич, кар түгелдер,
Ак хис түгелә күктән.
Һәй, юләр кар, салкын эзләп
Җиргә түгелмә бүтән.

Май ае һәм ябалак кар —
Бу мин күрмәгән хикмәт.
Гыйнварның чая егете
Май кызын тотып үпмәк.

Бу мин татымаган хистер,
Бу мин эчмәгән ләззәт.
Үткәннәрдән эзләп кайтыйм,
Кошлар, бирегез канат...

Киләсе ап-ак бәхетем,
Нарасый өметләрем,
Яшьлегемдә сөя алмый
Югалткан егетләрем
Кайтырсыз күк шушы язда,
Сагынып үткәннәрне.
Үткәннәрне ташкын сулар
Югач та көткәннәрне.

Кайтырсыз, түзә алмассыз,
Сөю чакырган җиргә.
Галәмдә җирнең үзен дә
Мәхәббәт әйләндерә.

## *Ишек тотkaң чәчәк аткан*

Сине исәр, диләр иде.
Исерек, диләр иде.
Үзе шундый гашыйк булган
Исереп, диләр иде.
Мин ул чакта көлдем генә,
Айныган идем бугай.
Иңнәремә тау ауганга
Кайгыда идем бугай.
Син көн дә чәчәк китердең,
Тоткама куеп киттең.
Күрше-күлән каршысында
Шундый ла хурлар иттең.
«Ишек тотkaң чәчәк аткан»,—
Диеп көлгәннәр иде.
Синең чынлап яратканны
Алар белгәннәр иде.
Инде мине исәр, диләр,
Исерек, диләр мине.
Үзе йөри мәхәббәттән
Исереп, диләр мине.
Мин көн саен гөлләр өзәм,
Тик саламын Иделгә.
«Ишек тотkaң чәчәк аткан»,—
Дип әйтсеннәр иде лә...
...Сагыш салларына ятып,
Гөлләр ага Иделдә...

## *Нигә әле...*

Син бүген, төшемә кереп,
Шакыдың ишегемне.
Нәкъ элекке кебек булды:
Кермимен, кичегелде.

Кулыңдагы чәчәкләрне
Тагы куйдың тоткама.
«Киттем,— дидең,— мине уйла,
Мине уйла, йоклама.

Шушы әмердән уяндым,
Сөю килгән таңым ла!
Нәкъ элеккечә ялгызлык
Чыңлап тора тагын да.

Нигә әле төшкә кердең?
Ник шакыдың ишекне?
Йөрәк тырпылдый читлектә,
Беркемне дә иш итми.

* * *

Төпкә батса да,
Тау башында ташлар.
Тауга менсә дә,
Җиргә ава башлар.

## *Көзге күлләвекләр*

Исеңдәме
Ул көз, ул сентябрь?
Исеңдәме яфрак яңгыры?
Зәңгәр күккә кошлар күтәрелгән.—
Саубуллашу өне яңгырый.

Исеңдәме,
Ул көз, ул сентябрь?
Исеңдәме җылы яңгыры?
Зәңгәр күлләвектә сары яфрак —
Мәктәп кыңгыравы яңгырый!

Исеңдәме,
Ул көз, ул очрашу!
Исеңдәме көзге ул тынлык!
Фәкать йөрәкләрне ишетергә
Икебез дә дәшми без тордык.

Көзге
күлләвекләр көзге иде.
Шул көзгедә күзләр очрашты.
Көзге күлгә, бөтен дөньясына
Сыймас мәхәббәтне без ачтык.
. . . . . . . . . . . . .
Шундый мәхәббәттән без качтык...

## *Югалтсаң...*

Ак йолдыз чакырды —
мин бардым.
Кагылдым — ул җиргә атылды,
мин яндым.
Ут булып мин күктә
кабындым.
Йолдызга табындым,
Йолдызга абындым.

...Югалткан җиреңне
...хәзер син тап инде.

## *Бәхет талы*

Очраштык та без икебез
Яр буена тал утырттык.
Тамырлары ныгыр микән,
Үлмәсләрме дип курыктык.

Таллар үсте... Йомшак-йомшак
Сары песи сабакларда.
Без бәхетле шулкадәрле
Иң бәхетле шул чакларда.

Ә беркөнне күрше карты
Шул талларны кыркып китте.
Безнең талдан оя үреп,
Ак казны бәхетле итте.

## *Кыяматкә хыянәт*

Бар мәетләр шытып чыгар
җир өстенә.
Бу көн булыр инде
кыямәт.
Җир өстендә күпме мәет
йөреп тора.
Киләчәккә генә түгел, ахры,
кыяматкә иттек
хыянәт.

## *Шикләнү*

Башкаларга мине алыштырдың.
Ялгыз калдым юллар чатында.
Үткәннәргә кайтып эзлим микән
Мәхәббәтне яшьлек атында?

Башкаларга, ах, мин сөйләр идем
Югалтуым, хатам хакында.
Дилбегәне тартам, әй, туктап тор,
Вакыт аты, сөю хакына...

Иркәләнеп яшьлек хыялларым
Җир-бишектә һаман атына.
Мөмкин булса, кайтыр идеме җир
Утлар чәчеп янган вакытына?

Шикләндерә шунсы чак кына.

## *Узган... уза...*

Дөнья көзгә узган икән:
Яфраклар ялкауланган,
Каеннар алкаланган,
Имәннәр ялкынланган.

Дөнья кышка узган икән:
Сөенеч чаналарга.
Сабырлык бирсен чәченә
Чал кергән аналарга.

Дөнья язга узган икән:
Йөрәккә тама тамчы.
Дөнья, зинһар, шул халәттә
Тагын бер фасыл калчы!

Дөнья җәйгә узган икән:
Гомер кичерә җәйләп.
Ямь-яшел күбек эченә
Үз-үзен куйган бәйләп.

Дөнья дөньялыктан узган,
Саклый гына күр аны:
Син аны тыңламаган көк,
Ул да сине тыңламый.
. . . . . . . . . . .
Тыңламый...

## *Ярлар ишелә*

— Әү, бәгырем!
Миңамы соң бу сүз?
Җаным эреп тама җаныңа.
Онытылам,
Һушым китеп бара,
Кайчан килермен, дим, аңыма.
— Әү, бәгырем!
Шул сүзләрең белән
Мин бөтенләй зәңгәр тәхеттә.
Юк, бу түгел бәхетең, диләр икән,
Кирәк түгел башка бәхет тә.

Син китергән газап дәрьяларын
соң тамчыга кадәр эчеп тә —
«Әү, бәгырем!» — диеп дәштең исә,
Сусау ала,
Сусау, ничек тә...

— Әү, бәгырем!
— Тукта!
— Юк, туктамыйк,
Туктау язык безнең ишегә,
Төбенә кадәр төшик, эчик, бәгырем.
Эчеп беткәч, ярлар ишелә...
...Без калырбыз бергә...
...Бергә-бергә...
...Гүрдә...

* * *

Ялгызлыкның чишмәләре...
Ах, серләрен чишмәүләре!
Ялгызлыкның тавы биек,
Тавы тулы явыз киек.

Ялгызлыкның юлы озын.
Төне озын, озын, озын.
Ялгызлыкның якыны юк,
Җылытырга ялкыны юк.

## *Башкаларга гына күчермә...*

Шулкадәрле сагынам, сагынам сине,
Әмма яннарыңа бармыйм, түзәм.
Чәйләр эчкәч, чынаяклар түгел,
Сабыр савытларым юып тезәм.

Төш җитүгә сабыр савытларым
Мөлдерәмә тула, тагын эчәм.
Шәфәкъ нурларында — алсу моңнар,
Елый-елый догаларга күчәм:

Йа Ходаем, кичер халәтемне,
Аңы сөюемне кичермә...
Диңгез кипсен, хәтта таулар күчсен,—
Мәхәббәтен генә күчермә.

Башкаларга гына күчермә...

* * *

Дөнья тузган, ап-ак тузан
Керә кара күзләргә.
Аяктан ега кискен җил,
Һич чара юк түзәргә.

Учлап-учлап алып сала
Җилкәләргә шул карны.
Бөтен тереклек оныткан
Җилсез мизгеле барны.

Бар да шаша, бар да кача.
Йә күмә, йә күмелә...
Бар булганы белән бу төн
Күмелеп калды күңелгә.

* * *

Идел — ярсу, мин — ямансу.
Ах, хикмәтле агымсу.
Йөрәк яна, эчим янә,
Иделләрдән алам су.

Мизгелләрне төяп ага
Чал Идел дулкыннары.
Идел — тирән, йөзеп керәм,
Тирән тормыш упкыннары.

Идел ага һаман ярсып,
Ярларында торам басып.
Яшәү дигән агымсуга
Җыр агызам шашып-шашып.

## *Беләбез... икебез дә*

Мин сине көтеп утырам,
Син башканы көтәсең.
Без белмибез көткәннәрнең
Башкаларга китәсен.

Син аны көтеп йөрисең,
Ә ул көтә башканы.
Башкаларның йөрәгендә
Ул бәхетен ачканмы?

Юк, һәм син дә ачмагансың...
Ләкин башка бит, кызык.
Инде кайсы тарафларга
Китеп барасың кызып?

Миңа?
Миңа башка кирәк,
Инде син кирәкмисең.
Айсыз, кояшсыз калдырдың
Моң тулы йөрәкне син.

Син бит әле дә көтәсең.
Мин дә сине көтәмен.
Һәм беләсең инде минем
Башкаларга китәсем.

## *Телефонда яшьлек*

Өзеп ташлыйм микән телефонны?
Ташымасын миңа моң, сагыш.
Онытылып беткәч, бүген тагы
Яшьлегемнән килде бер тавыш.

Чишмә аккан кебек, таныш чишмә,—
Бу, әлбәттә, аның көлүе...
Тышауланган толпар йөрәккәем.—
Гомернең бу нинди мизгеле?

Чәчләремә кунган ап-ак уйлар.
Трубканы кыскан карт куллар.
Чыбык аша һаман чишмә ага —
Вакыт нинди каты хөкемдар...

Өзеп ташлыйм микән бу арасын,
Гомеремнең бөтәү ярасын...
Мәхәббәтсез... үтеп булырмы соң
Өем белән кабер арасын?
Анда да бит җирдән барасы.

ЦБС ... АССР
абонемент



40089-29054

# *Эчтәлек*

**Уйга — юл, җанга — җылы!**


Юк, килмәсен миңа охшаш таңнар . . . . . . 6
Җанавылда туып үскән без . . . . . . . . . . 8
Туктап тормый дөнья . 9
Үз-үземә генә... . . . . 10
Менә шулай!.. . . . . . 10
Тукайга дәшү . . . . . 12
Кисәтәләр безне Исхакыйлар . . . . . . . . 14
Шагыйрь белән сөйләшү 15
Кеше — шигырь... . . . . . 16
Язгы этюдлар . . . . . 18
Төн — төер... . . . . . . . 19
Яшәүнең күге лә мин . 20
Шәһәр тәрәзеннән карап... 21
«Идел суы...» . . . . . 22
Уйга — юл, җанга — җылы! 23
Шул чагында, бәлки... . 24
Көткәндә . . . . . . . 25
Яшьлек атавында . . . 26
Үтеп барышлый . . . . 27


**Чалы кошы**


Башка язмыш юктыр... 30
«Учак яна...» . . . . . . . 31
«Җир бар...» . . . . . . 31
«Исерекләр илне баскан...» 31
Ачыл, бөре!.. . . . . . . 32
Яшел юлдан . . . . . . . 33
Уйны өткән мизгелләр . 34
Кояш белән сөйләшү . . 35
«Шаша-таша...» . . . . . 35
Күзге таган . . . . . . 36
«Аквариум балыгына...» 37
«Иртәгәгә кабызырга...» 37
«Дөнья бер...» . . . . . 37
Башкача юк . . . . . . 38
Кыр казлары минем халәттә . . . . . . . . . 39
Төрмәләр һәм парламентлар... . . . . . . . . 40
Утлы уй . . . . . . . . 41
«Төн...» . . . . . . . . 42
Үзгәрә икән заман... . . . 43
Ә мин... . . . . . . . . 44
Ә үзем ышанмыйм . . . 44
Җанны чөя... . . . . . . . 45
Әгәр шулай булса . . . 46
Кирәк иде... . . . . . . . 46

Мин дә йоклар идем... . 47
Котлыйм . . . . . . . 48
Чалы кошына . . . . . 49
Үзгәртеп кору . . . . . 50
Әллә... . . . . . . . . . 51
«Уйлаганым тора...» . . 52

**Кыя карагае**

Дисеннәр... . . . . . . . 54
Ишетәсеңме?.. . . . . . 56
Синнән миңа... . . . . . 56
Синең җаның . . . . . 57
Дисәң... . . . . . . . . 57
Шагыйрьгә җавап . . . 58
«Хыялга ияреп киттем...» 59
Синнән . . . . . . . . 59
Шулай була . . . . . . 60
Үзем... бары тик үзем... 60
Каз өмәсе . . . . . . . 61
Тәрәзләрең синең . . . 62
Әмма... . . . . . . . . 63
«Уттан алып суга...» . . 63
Көтәм . . . . . . . . . 64
«Мин сине дә укып чыктым...» . . . . . . . . 64
Булмый бит... . . . . . . 65
«Мәхәббәткә ышандырып...» . . . . . . . . . 65
Ярар ла ул... . . . . . . 66
Булмый . . . . . . . . 67
Сөю? Чәчкә — чәч! . . . 68
«Син миңа һәрвакыт, сөю...» . . . . . . . . . 69
«Синнән миңа берни кирәк түгел...» . . . . . . 70
Әллә нинди җыр бу . . 70
Ник кагылдың син, ә? . 71
Ә нигә? . . . . . . . . 72
Әгәр дә уйлаганда . . . 73
Яфрак булыр көннәр бар... . . . . . . . . . 74
Егет җыры . . . . . . 76
Мираж . . . . . . . . 77
Үпкәләшкәч . . . . . . 78
«Яратасыңмы — ярат...» . 78
Ничек ышаныйм? . . . 79
Юктыр... юктыр... . . . 80
Ялгыз калдым . . . . . 81
Пар аккошлар арасында 82
Мәхәббәткә күз йому . 83
Ди-ва-на! . . . . . . . 84
Кыя карагае . . . . . . 85
Җилгә сал... салма... . . 86
Төшләр... . . . . . . . 86
Сагыну . . . . . . . . 88

**Төн — минеке**

Әгәр белсә... . . . . . . 90
«Язмышыма яр кирәк...» 91
«Саумы, төн, айсыз, йолдызсыз...» . . . . . . . 91
Тик бер атна... . . . . . 92
«Көтмәгәндә яңгыр явып үтте...» . . . . . . . . 93
Беренче һәм соңгы . . . 93
Яфрак — язмыш . . . . 94
Төн — минеке! . . . . . 95

Ә ай белеп көлә... . . . 96
Йә йоклама, йә уянма... 96
Зәңгәр юрган . . . . . 97
Аңлашу . . . . . . . . 98
Яшенле мәхәббәт . . . 99
Яңа ялгызлык . . . . . 100
Синең күзләр . . . . . 101
Мин — мәхәббәт . . . . 102
Сиңа да, миңа да . . . 103
Беләбез бит . . . . . . 104
Булмый . . . . . . . . 104
Әле син белмисең... . . 105
«Җир кадәрле авыр икән сөю...» . . . . . . . . . 106
Таштай бөре дә ачыла . 106
Без бергә генә юк... . . 107
«Елга ташы, мунча ташы...» . . . . . . . . . 108
Сәер сөенеч . . . . . . 108
Мин генә... . . . . . . . 109
Ничек үпкәләттем икән?.. 110
Ул чакта да... . . . . . . 111
Гөнаһ алмасы . . . . . 112
Йөрәктә май бураны . . 113
Ишек тоткаң чәчәк аткан 114
Нигә әле... . . . . . . . . 115
«Төпкә батса да...» . . . 115
Күзге күлләвекләр . . . 116
Югалтсаң... . . . . . . 117
Бәхет талы . . . . . . 117
Кыяматкә хыянәт . . . 118
Шикләнү . . . . . . . . 118
Узган... уза... . . . . . 119
Ярлар ишелә . . . . . 120
«Ялгызлыкның чишмәләре...» . . . . . . . . . 121
Башкаларга гына күчермә... . . . . . . . . . . 121
«Дөнья тузган, ап-ак тузан...» . . . . . . . . . 122
«Идел — ярсу, мин — ямансу...» . . . . . . . . . 122
Беләбез... икебез дә . . 123
Телефонда яшьлек . . . 124

Литературно-художественное издание

*Сафина Назиба*

*РАННЯЯ ПТИЦА*

Стихи

(на татарском языке)

Мөхәррире *Ф. Зыятдинова*
Рәссамы *И. Азимов*
Бизәлеш мөхәррире *Р. Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире *А. Газизҗанова*
Корректоры *Г. Хәбибуллина*

ИБ № 6770

Җыярга тапшырылды 21.08.97. Басарга кул куелды 3.11.97. Форматы $70 \times 100\,^1/_{32}$. Типогр. кәгазе № 2. «Тип-Таймс» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 5,2. Шартлы буяу-оттиск 5,53. Нәшер-хисап табагы 4,34. Тиражы 3000 экз. Заказ Н-480.

Татарстан китап нәшрияты.
420503. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство.
420503. Казань, ул. Баумана, 19.

Татарстан газета-журнал нәшрияты типографиясе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.

